**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«19» октября 2020 г** **№ 14**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 1 пункты һәм 44 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты турында» муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Китерелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органында теркәргә.
3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын теркәү өчен җаваплы итеп «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы Р.Г. Кәлимуллинны билгеләп куярга.
4. Әлеге карарның һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставында каралган тәртиптә рәсми рәвештә муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән соң 7 эш көненнән дә соңрак булмаган срокта бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итәргә.
5. Әлеге карар һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы әлеге карарның 4 пунктында каралган тәртиптә аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
6. Әлеге карар һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы»

муниципаль берәмлеге Уставы үз көченә кергән моменттан, Советның 2015 елның 21 сентябрендәге 7 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында» (Советның 28.09.2016 N 86, 29.11.2016 N 110, 26.05.2017 N 145, 29.10.2018 №255 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Карарын һәм Россия Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә 2015 елның 16 октябрендә № RU165160002015001 номеры белән теркәлгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 28.09.2016 N 86, 29.11.2016 N 110, 26.05.2017 N 145, 29.10.2018 №255 карарлары белән белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчләрен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль районы Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

## I бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба әлеге Устав тексты буенча - Устав) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә халыкның катнашуы формаларын, тәртибен һәм гарантияләрен, җирле үзидарә органнарының, җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының структурасын, формалаштыру тәртибен һәм вәкаләтләрен, җирле үзидарәнең икътисадый һәм финанс нигезләрен һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә аларның үтәлеше гарантияләрен билгели.

2. Устав Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актлары системасында югары юридик көч акты булып тора, Биектау муниципаль районының бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә була һәм кулланыла.

### 2 статья. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының исеме һәм статусы

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законы белән төзелгән һәм статус бирелгән муниципаль берәмлек булып тора.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» (алга таба әлеге Устав тексты буенча - район), кыскартылган исеме - «Биектау муниципаль районы».

3. Районның административ үзәге булып Биектау тимер юл станциясе бистәсе тора.

### 3 статья. Районның территориаль төзелеше

1. Биектау муниципаль районы территориясен Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре тәшкил итә:

Айбаш авыл җирлеге: Айбаш (административ үзәк), Олы Көек, Яңавыл, Апсабаш, Каракүл, Кодаш авыллары;

Алан-Бәксәр авыл җирлеге: Алан-Бәксәр (административ үзәк), Алат спиртзаводы, Гәр, Әсән, Шөмлән авыллары;

Әлдермеш авыл җирлеге: Әлдермеш (административ үзәк), Сая, Өбрә авыллары;

Каенлык авыл җирлеге: Каенлык (административ үзәк), Өнсә, Мамонино, Чыршы, Шуман, Абла, Бәерле, Олы Пүчинкә, Кече Пүчинкә, Олыяз, Соловцово, Тимофеевка авыллары;

Бөреле авыл җирлеге: Бөреле җәнлек совхозы бистәсе (административ үзәк), Пимәр, Сосновка, Керосиново, Кирилловка авыллары, Бөреле тимер юл разъезды

бистәсе;

Олы Битаман авыл җирлеге: Олы Битаман (административ үзәк), Бикнарат, Кече Битаман, Ювас авыллары;

Олы Кавал авыл җирлеге: Олы Кавал (административ үзәк), Чуаш иле, Маҗар, Кече Кавал авыллары;

Биектау авыл җирлеге: Биектау (административ үзәк), Пановка, Пермяк, Калинино, Келәтле, Эстачи авыллары, Инеш бистәсе;

Дачный авыл җирлеге: Дачный бистәсе (административ үзәк), Яшь Көч авылы;

Дөбъяз авыл җирлеге: Дөбъяз (административ үзәк), Олы Солабаш, Кече Солабаш, Таршна, Торнаяз, Шыпшыек авыллары;

Иске-Казан авыл җирлеге: Коркачык (административ үзәк), Камай, Татар Әйшәсе, Югары Ия, Кызылкүл, Рус Урматы, Татар Урматы авыллары;

Казаклар авыл җирлеге: Казаклар (административ үзәк), Өлә, Матмыр, Наратлык авыллары;

Красносельский авыл җирлеге: Биектау тимер юл станциясе бистәсе (административ үзәк), Березовка, Яңа Поселок, «Каменка» шифаханәсе, Урманчы бистәләре, Киндерле тимер юл разъезды бистәсе;

Коркачык авыл җирлеге: Коркачык тимер юл разъезды бистәсе (административ үзәк);

Мәмдәл авыл җирлеге: Мәмдәл авылы (административ үзәк), Юртыш бистәсе;

Мүлмә авыл җирлеге: село Мүлмә (административ үзәк), Красна, Сасмак, Тимерче авыллары, Кызыл-Болгар бистәсе;

Алат авыл җирлеге: Алат (административ үзәк), Кече Алат, Потаниха, Урта Алат авыллары;

Семиозерка авыл җирлеге: Семиозерка (административ үзәк), Шигали, Макаровка, Теплый Ключ авыллары, Күлле, Якты күл бистәләре;

Суыксу авыл җирлеге: Суыксу (административ үзәк), Олы Рәс, Кондырлы, Кече Рәс, Ташсу, Чәмәк авыллары;

Ташлы-Кавал авыл җирлеге: Ташлы-Кавал (административ үзәк), Глухово, Рус-Татар Әйшәсе, Туктамыш, Өмбе авыллары;

Усад авыл җирлеге: Усад (административ үзәк), Хохлово, Ильино, Садилово, Толмач, Тимофеевка, Чубар авыллары;

Чыпчык авыл җирлеге: Чыпчык (административ үзәк), Байкал, Кече Бөреле, Иске Бөреле авыллары;

Чернышевка авыл җирлеге: Чернышевка (административ үзәк), Каймар, Ивановка, Яңа Мамонино, Иске Тура, Шушар авыллары;

Шәпше авыл җирлеге: Шәпше (административ үзәк), Кызыл Шәрекъ, Тимошкино авыллары;

Ямаширмә авыл җирлеге: Ямаширмә (административ үзәк), Олы Ялан, Здоровый Ключ авыллары.

3. Район чикләре «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән.

4. Район чикләре җирлекара характердагы мәсьәләләрне хәл итү өчен районның

җирле үзидарә органнары тарафыннан шартлар тудыру кирәклеген исәпкә алып, шулай ук районның бөтен территориясендә күрсәтелгән органнарга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән.

5. Район чикләрен үзгәртү Биектау муниципаль районының халык, җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законы белән гамәлгә ашырыла.

**4 статья. Районның рәсми символлары**

1. Районның үз рәсми символлары - тарихи, мәдәни һәм башка җирле традицияләрне һәм үзенчәлекләрне чагылдыручы флагы, гимны һәм гербы бар.

2. Рәсми символларның тасвирламасы, алардан файдалану тәртибе «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы раслаган район флагы, гимны һәм гербы турындагы Нигезләмәләр белән билгеләнә.

3. Район гербы сурәте район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының матбугат, бланк һәм башка рәсми документларында, районның җирле үзидарә органнары фасадларында, район Советының утырышлар залында, Район Башлыгының һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесенең эш кабинетларында урнаштырыла. Район гербын рәсми рәвештә урнаштыруның башка очраклары район Советы карары белән билгеләнә.

4. Район флагы даими рәвештә җирле үзидарә органнары биналары, предприятиеләр, учреждениеләр, муниципаль милектәге оешмалар фасадында, Район Советының утырышлар залында, Район Башлыгының һәм Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең эш кабинетларында урнаштырыла. Район флагыннан рәсми файдалануның башка очраклары Район Советы һәм Район флагы турындагы Нигезләмә карарлары белән билгеләнә.

5. Районның гербы һәм флагы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узарга тиеш.

**5 статья. Халыкның районда җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга хокукы**

1. Районда үзидарә Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашу юлы белән, турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка формалары ярдәмендә, шулай ук әлеге Уставта каралган җирле үзидарәнең сайлаулы һәм башка органнары аша гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне нинди җенескә, расага, милләткә, телгә, чыгышка, мөлкәти һәм вазыйфаи хәлгә, дингә мөнәсәбәткә, инануларга, иҗтимагый берләшмәләргә карауга бәйсез рәвештә турыдан-туры да, шулай ук вәкилләр аша да гамәлгә ашыруга бертигез хокукларга ия.

Район территориясендә даими яисә башлыча яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия.

3. Районның һәр кешесе җирле үзидарә органнарына һәм районның җирле үзидарәсе вазыйфаи затларына турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, җирле үзидарә

органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

4. Район җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары һәркемгә аның хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук, законда башкасы каралмаган очракта, гражданнарның районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында тулы һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

5. Районның җирле үзидарә органнары массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысул белән халыкка районның һәм аның аерым территорияләренең аеруча әһәмиятле мәсьәләләре, гомуми файдаланудагы транспорт, торак-коммуналь хуҗалык эше, халыкка төрле хезмәтләр күрсәтүче социаль-мәдәни һәм башка учреждениеләр һәм хезмәтләр күрсәтү челтәре үсешен, социаль ташламалар, җәмәгать тәртибен саклау торышы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» Федераль закон нигезендә даими рәвештә халыкка мәгълүмат бирә.

6. Гражданнар, оешмалар, әгәр аларның хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судта шикаять белдерергә хокуклы.

**6 статья. Районның җирле үзидарә органнары структурасы**

1. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары структурасын түбәндәгеләр тәшкил итә:

1) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы (алга таба әлеге Устав тексты буенча - район Советы);

2) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы (алга таба әлеге Устав тексты буенча - район Башлыгы);

3) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба әлеге Устав тексты буенча - район башкарма комитеты);

4) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының контроль-хисап палатасы (алга таба әлеге Устав тексты буенча - районның Контроль-хисап палатасы).

2. Муниципаль районның җирле үзидарә органнарын төзү, аларның вәкаләтләре, вәкаләтләре срогы, хисап бирү, контрольдә тоту тәртибе, шулай ук күрсәтелгән органнарны оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең башка мәсьәләләре әлеге Устав тарафыннан Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнә.

3. Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары системасына керми.

4. Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү турында район Советы карары 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән карарны кабул иткән район Советының вәкаләтләре чоры тәмамлангач кына үз көченә керә.

**7 статья. Районның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләре**

1. Районның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль район бюджеты проектын төзү һәм карау, муниципаль район бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, муниципаль район бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

2) муниципаль район җирле салымнар һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

3) муниципаль районның муниципаль милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) муниципаль район чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;

5) муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

6) муниципаль район чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру һәм җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен шартлар тудыру;

7) террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук муниципаль район территориясендә террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу;

8) милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен яклауга һәм үстерүгә, җирле аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

9) муниципаль район территориясендә гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен кисәтүдә һәм бетерүдә катнашу;

10) муниципаль район территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны муниципаль милиция тарафыннан оештыру;

11) муниципаль районның хезмәт күрсәтә торган административ участогында эшләү өчен полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә бина бирү;

12) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфа буенча вазыйфаларын үтәү чорына торак урыны бирү;

13) әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру;

14) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү

программалары буенча (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне, карап тотуны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, балаларның гомерен һәм сәламәтлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тудыру;

15) муниципаль район территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру (аерым территорияләр халкын медик-санитар тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән җирлекләр территорияләреннән тыш);

16) муниципаль район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау), җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;

17) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемаларын раслау, муниципаль район территориаль планлаштыру схемасы нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау, муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару, муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗ өчен резервлау һәм тартып алу, хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш параметрларының җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына һәм рөхсәт ителешенә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү, хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә, Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә авылара территориядә урнашкан үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул итү, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез корылманы сүтү яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы карар, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген тартып алу турындагы карар кабул итү,

авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез корылманы сүтүне гамәлгә ашыру яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү;

18) реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау, муниципаль район территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтләр бирү, мондый рөхсәтләрне гамәлдән чыгару, 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль район территориясендә үз белдеге белән урнаштырылган реклама конструкцияләрен сүтү турында күрсәтмәләр бирү;

19) җирлекләрнең архив фондларын саклауны да кертеп муниципаль архивны формалаштыру һәм карап тоту;

20) муниципаль район территориясендә җирлекара җирләү урыннарын карап тоту, ритуаль хезмәтләр оештыру;

21) муниципаль район составына керүче җирлекләрне элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

22) җирлекара китапханәләр тарафыннан халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, аларны комплектлау һәм аларның китапханә фондларының сакланышын тәэмин итү;

23) муниципаль район составына керүче җирлекләрне ял вакытын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

24) муниципаль район составына керүче җирлекләрдә җирле традицион халык сәнгате иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру;

25) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау;

26) муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен муниципаль район бюджеты акчалары хисабына тигезләү;

27) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, муниципаль район халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

28) муниципаль район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге аеруча сакланулы табигый территорияләрне файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

29) муниципаль район территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

30) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

31) җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү өчен шартлар тудыру, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү, социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ирекleләр хәрәкәтенә (волонтерлыкка) ярдәм итү;

32) муниципаль район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, муниципаль районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

33) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

34) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү;

35) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

36) муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү, федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру;

37) муниципаль район чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру;

38) адреслау объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юк итү, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

39) муниципаль районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

40) 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.

2. Районның җирле үзидарә органнары муниципаль район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән аларга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тиешле җирлекләр бюджетларына муниципаль район бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

**8 статья. Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокукы**

1. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль район музейларын төзү;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

4) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә ярдәм күрсәтү һәм муниципаль район территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

5) 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагындагы муниципаль мәгариф югары белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен гамәлгә ашыру;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

9) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

10) «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыру;

11) авылара территориядә урнашкан торак пунктта нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

12) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

13) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»гы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

14) инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын үстерүгә, адаптив физик культурага һәм адаптив спортына ярдәм күрсәтү;

15) 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына әлеге вазыйфаны хезмәткәр биләгән вакытка торак урыны бирү.

2. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашырга (131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә аларга тапшырылмаган), әгәр бу федераль законнарда каралса, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән үз компетенцияләреннән төшереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан тыш, җирле бюджетлар керемнәре исәбеннән һәм күчерүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керүдән тыш, хәл итәргә хокуклы.

**9 статья. Районның авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган районның җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләре**

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;

2) аларда машина кую урыннарын (парковка урыннарын) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне кертеп, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

3) авыл җирлекләрендә яшәүчеләрне һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

4) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

5) авыл җирлекләре чикләрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу;

7) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм алардан килгән зыяннарны бетерүдә катнашу;

8) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, авыл җирлекләре китапханәләренең китапханә фондларын комплектлау һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

9) авыл җирлекләре милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау;

10) авыл җирлекләрендә җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

12) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан авыл җирлекләре урманнарыннан, аеруча саклаулы табигатый территорияләр урманнарыннан файдалану, аларны саклау, яклау, аларны торгызу;

13) авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда объектлар файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле

нормативларын раслау, муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен тартып алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, биналарны, корылмаларны карауны һәм мондый карау барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашыру, хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яки реконструкция объектының яисә бакча йортының (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) планлаштырыла торган төзелеш параметрларының җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына һәм рөхсәт ителешенә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү, хәбәрнамәдә күрсәтелгән планлаштырыла торган индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә, максатчан билгеләнештә кулланылмый торган яки Россия Федерациясе законнарын бозып кулланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карарлар, рөхсәтсез корылманы сүтүне яисә аны җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкциянең чик параметрларына, территорияне планлаштыру буенча документация белән, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләренә туры китерүне гамәлгә ашыру;

14) «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү системасы схемасында җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чараларын җылылык белән тәэмин итүнең бердәм оешмасы тарафыннан үтәлүенә җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

15) авыл җирлекләре территориясендә авария-коткару хезмәтләрен һәм (яисә) авария-коткару формированиеләрен төзү, карап тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

16) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

17) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, җирлек халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

18) авыл җирлекләре территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге аеруча саклаулы табигать территорияләрен файдалану һәм саклау

өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

19) Россия Федерациясенең су законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, аларны куллануны чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү;

20) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

21) җирлекләрдә хезмәт күрсәтә торган административ участокларда полиция участогы вәкаләтле затлар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә эш урыннары бирү;

22) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полициянең участок уполномоченные вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына хезмәткәрләр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфалар буенча бурычларны үтәү чорында торак урыннары бирү;

23) коммерцияле булмаган оешмалар турында «Федераль законның 31.1 һәм 31.3 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү»;

24) авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре төзү өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү, 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы «Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында һәм шартнамә төзү хокукына ия булуга ачык аукцион уздыру;

25) авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру;

26) 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы “Кадастр эшчәнлеге турында” Федераль закон нигезендә поселок территориясендә Комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу;

27) полициянең участок уполномоченные вазыйфаларын биләүче хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфалар буенча бурычларны үтәү чорында торак урыны бирү.

**10 статья. Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү**

Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре бирү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

Районның җирле үзидарә органнары әлеге максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру дәүләт контролендә тора. Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны контрольдә тоту шартлары һәм тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә. Район Советы үз вәкаләтләре чикләрендә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен районның җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану очраклары һәм тәртибен билгеләргә хокуклы.

**11 статья. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы**

Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы федераль законнар һәм җирле үзидарә турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**12 статья. Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре**

Районның җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

1) район җирле үзидарә органнарының Районның социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән дәүләт программаларын тормышка ашыруда катнашуы;

2) район җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яисә вакытлыча координацияләү, консультатив, киңәшмә һәм башка эшче органнар булдыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында район Советының закон чыгару инициативасы;

5) законнарда билгеләнгән хезмәттәшлекнең башка формалары.

**13 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу**

Районда муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне, муниципаль хезмәткәр статусын, муниципаль хезмәт узу шартларын һәм тәртибен дә кертеп, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексы, район Советы белән расланган Муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә һәм район муниципаль хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

## II бүлек. ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУ ФОРМАЛАРЫ

**14 статья. Халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда турыдан-туры катнашуы**

Гражданнар турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыралар һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда түбәндәге формаларда катнашалар:

1) җирле референдум;

2) Районның чикләрен үзгәртү һәм үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;

3) гражданнарның хокукый актлар чыгару инициативасы;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә;

5) гавами тыңлаулар;

6) гражданнар җыелышы;

7) граждан конференциясе (делегатлар җыелышы);

8) гражданнарны сораштыру;

9) җирле әһәмияттәге иң мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы;

10) җирле үзидарә органнарына гражданнарның мөрәҗәгатьләре;

11) иҗтимагый (консультатив) советлар оештыру;

12) Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар.

**15 статья. Җирле референдум**

1. Җирле референдум турыдан-туры Район халкы тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында үткәрелә.

2. Җирле референдум районның бөтен территориясендә 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон һәм 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

3. Җирле референдумда яшәү урыны район чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы. Россия Федерациясенең халыкара килешүләре нигезендә һәм законда билгеләнгән тәртиптә, район территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары Россия Федерациясе гражданнары да булган шул ук шартларда җирле референдумда катнаша.

4. Җирле референдум билгеләү турындагы карар район Советы тарафыннан түбәндәгеләр инициативасы буенча кабул ителә:

1) җирле референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнар;

2) сайлау берләшмәсе, уставлары сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашуын күздә тоткан һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән башка иҗтимагый берләшмә;

3) Район Советы һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесе алар белән берлектә тәкъдим ителгән.

5. Гражданнар, сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый оешмалар инициативасы буенча җирле референдум билгеләү шарты булып, әлеге инициативаны яклап имзалар җыю тора, аларның саны район территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санының биш процентын тәшкил итәргә тиеш, ләкин ул 25 имзадан да ким була алмый.

6. Район Советы һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән берлектә тәкъдим ителгән референдум үткәрү инициативасы Район Советы карары һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән инициативаны тәкъдим итү тәртибе район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

7. Район Советы җирле референдумны район Советына документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә билгели, алар нигезендә җирле референдум билгеләнә.

8. Референдумда тавыш бирүне үткәрү датасы билгеләнгән көнгә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча, район Советы карары буенча аны дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына билгеләнгән сайлауларда тавыш бирү көне яисә башка билгеләнгән референдумда тавыш бирү көне белән бергә кушу максатларында соңрак срокка (ләкин 90 көннән дә артык түгел) күчерелергә мөмкин.

9. Референдум билгеләү турындагы, шулай ук әлеге статьяның 8 пункты нигезендә референдумда тавыш бирү көнен күчерү турындагы карар массакүләм мәгълүмат чараларында аны кабул иткән көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

10. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

11. Җирле референдумда кабул ителгән карар район территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш һәм дәүләт хакимиятенең нинди дә булса органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

12. Районның җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлешен әлеге Устав билгеләгән алар арасында вәкаләтләр бүлешү нигезендә тәэмин итәләр.

13. Җирле референдум уздыру турындагы карарга, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карарга федераль законнар нигезендә гражданнар, җирле үзидарә органнары, прокурор, федераль закон белән вәкаләтләр бирелгән дәүләт хакимияте органнары тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

**16 статья. Район чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү күрсәтелгән чикләрне үзгәртүгә, районны үзгәртеп коруга халыкның ризалыгын алу максатларында уздырыла.

2. Муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү, муниципаль районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү муниципаль берәмлекнең бөтен территориясендә яки аның территориясе өлешендә 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның12 статьясының 2 һәм 3 өлешләре һәм 13 статьяның 5 өлеше нигезендә үткәрелә.

3. Район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү район Советы тарафыннан билгеләнә һәм 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда һәм 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законында, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

4. Район чикләрен үзгәртү, район яңарышы мәсьәләләре буенча тавыш бирү,

әгәр анда сайлау хокукына ия район яисә район өлеше халкының яртысыннан күбрәге катнашса узган дип санала. Район чикләрен үзгәртүгә, районны үзгәртеп коруга халыкның ризалыгы, күрсәтелгән үзгәреш өчен тавыш бирүдә катнашкан район халкының яисә район өлешенең яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, алынган дип санала.

5. Чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары һәм кабул ителгән карарлар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**17 статья. Район Башлыгын, Биектау муниципаль районы Советы депутатын сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алу тәртибе**

1. Биектау муниципаль районы Советы депутаты, муниципаль район Башлыгы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында, җирле референдум уздыру өчен» Татарстан Республикасы Законында каралган тәртиптә, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, халык инициативасы буенча кире чакыртып алынырга мөмкин.

2. Биектау муниципаль районы Советы депутатын чакыртып алу өчен нигез булып закон көченә кергән суд карарында билгеләнгән түбәндәгеләр тора:

а) системалы рәвештә (3 тапкырдан артык) муниципаль район Советы депутатының муниципаль район Советы утырышларында җитди сәбәпләрсез катнашмавы;

б) Биектау муниципаль районы Советы депутаты вазыйфаларын үтәүдән 4 айдан артык вакытка депутатның үз-үзен читләштерүе, шул исәптән авыруы сәбәпле;

в) гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен карау буенча йөкләмәләрне күп тапкырлар (3 тапкырдан артык) үтәмәү, шул исәптән мөрәҗәгатьләрне дәлилсез игътибарсыз калдыру;

г) депутат тарафыннан муниципаль берәмлектә яшәүчеләрнең хокукларын бозуга китергән гамәлләрне (гамәлләрне яисә гамәл кылмауларны) башкару;

д) Биектау муниципаль районы Советы депутаты статусына туры килми торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

е) депутат тарафыннан Россия Федерациясе гражданының, чит ил гражданының, шулай ук юридик затларның намусын, абруен яисә эшлекле репутациясен таплый торган гамәлләр башкару;

ж) депутатның депутатлык вәкаләтләрен башкарган чорда суд тәртибендә террорлык яки экстремистик дип танылган оешмаларда әгъзалыгы;

з) муниципаль берәмлекләр Уставларында билгеләнгән башка нигезләр.

Нигезле сәбәпләргә медицина документлары белән расланган муниципаль район Советы депутатының, аның якын туганнарының Россия Федерациясе Гаилә кодексы белән андый дип танылган авыруы, шулай ук Биектау муниципаль районы Советы Регламентында билгеләнгән башка сәбәпләр керә;

2. Муниципаль район Башлыгын чакыртып алу өчен суд карары белән закон көченә кергән билгеләнгән түбәндәгеләр нигез була:

1) системалы рәвештә гамәлдәге законнарга каршы килә торган муниципаль хокукый актлар кабул итү;

2) муниципаль район Башлыгының үз вазыйфаларын җитди сәбәпләрсез системалы рәвештә үтәмәве;

3) әлеге Уставның муниципаль районы Башлыгы тарафыннан системалы рәвештә бозылуы;

4) муниципаль район Башлыгы тарафыннан муниципаль район халкының хокукларын күпләп бозуга китергән муниципаль хокукый актлар кабул итү, эшчәнлек (гамәлләрне яисә гамәл кылмауларны) кылу.

Системалылык дигәндә әлеге пунктта вәкаләтләр чоры дәвамында 3 (өч) һәм аннан да күбрәк гамәлләр кылу аңлашыла.

3. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын тәкъдим итү һәм тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю өчен тиешле сайлау округы территориясендә яшәүче сайлаучылар санынннан кимендә 10 (ун) кеше санында инициатив төркем төзелә.

Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча инициатив төркем Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча инициатив төркемне теркәү турында әлеге Уставның 59 статьясында күрсәтелгән сайлау комиссиясенә үтенечнамә белән мөрәҗәгать итә.

Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча инициатив төркемне теркәү турында үтенечнамә алу хакында әлеге Уставның 59 статьясында күрсәтелгән сайлау комиссиясе Биектау муниципаль районы Советы депутатына, муниципаль район Башлыгына кичекмәстән хәбәр итә һәм әлеге затларга гаризаның һәм аңа кушып бирелгән документларның күчермәләрен тапшыра.

4. Әлеге Уставның 59 статьясында күрсәтелгән сайлау комиссиясе Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча инициатив төркем документларын алган көннән алып 15 (унбиш) көн эчендә чакыртып алу өчен нигезләрнең әлеге Уставка туры килү-килмәү предметына тикшерергә, шулай ук чакыртып алу инициативасын күрсәтү тәртибенең үтәлешен тикшерергә тиеш. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Уставның 59 статьясында күрсәтелгән сайлау комиссиясе инициатив төркемне теркәү турында, яки әлеге инициатив төркемне теркәүдән баш тарту турында, мондый баш тартуның сәбәпләрен мәҗбүри күрсәтеп, карар кабул итәргә тиеш.

5. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүне оештыручы затлар Биектау муниципаль районы Советы депутатына, муниципаль район Башлыгына чакыртып алуга кагылышлы мәсьәләләрне карау вакыты һәм урыны турында хәбәр итәргә тиеш.

6. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча инициатив төркем әлеге инициативаны хуплап тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучылар имзаларын җыюны оештыра.

7. Имзалар җыю Биектау муниципаль районы депутатын муниципаль район Башлыгы чакыртып алу буенча инициатив төркем теркәлгән көннән соң икенче көндә башлана һәм инициатив төркем теркәлгән көннән соң 20 (егерме) календарь көн узгач тәмамлана. Әгәр әлеге пунктта билгеләнгән вакытта кирәкле имзалар саны җыелмаса, Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча кабат инициатива Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча инициатив төркем теркәлгән көннән бер ел эчендә карала алмый.

8. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү шарты булып тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның кимендә 5 (биш) проценты чакыртып алу инициативасын яклавы тора.

9. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар әлеге Уставның 59 статьясында күрсәтелгән сайлау комиссиясеннән чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү турында тиешле документлар кергән көннән соң 30 (утыз) көн эчендә муниципаль район Советы тарафыннан кабул ителергә тиеш, шул исәптән инициатив төркем тарафыннан тапшырылган имзалар кәгазьләрен тикшерү буенча да.

10. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирер алдыннан агитация уздырганда, шулай ук чакыртып алу процедурасының барлык башка этапларында әлеге затларга чакыртып алу нигезләре буларак күрсәтелә торган хәлләр турында аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелә. Муниципаль район аппараты Советы сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен чакыртып алынучы затларга бина, шулай ук муниципаль районның муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару чыганагы булган вакытлы матбугат басмасында, Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район башлыгын чакыртып алу процедурасы чорына ике тапкыр түләүсез бастырып чыгару мөмкинлеген бирергә тиеш.

11. Муниципаль район вәкилләре җыелышы депутаты, муниципаль район Башлыгы, әгәр чакыртып алу өчен тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның кимендә яртысы тавыш бирсә, чакыртып алынган дип санала.

12. Биектау муниципаль районы Советы депутатын, муниципаль район Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар муниципаль районның муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару чыганагы булган вакытлы матбугат басмасында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

**18 статья. Гражданнарның хокукый актлар чыгару инициативасы**

1. Район халкы әлеге Устав һәм район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә хокукый актлар чыгару инициативасы белән чыгыш ясарга хокуклы.

2. Сайлау хокукына ия район халкы санының 3 процентыннан артмаган санда сайлау хокукына ия булган гражданнар төркеме хокукый актлар инициативасы белән чыгыш ясарга мөмкин.

3. Хокукый актлар чыгару инициативасын гамәлгә ашыру максатларында район

халкы хокуклы:

- яшәү (эш) урыны буенча гражданнар җыелышларын һәм фикер алышу һәм хокукый инициатива күрсәтү буенча башка коллектив чаралар оештырырга һәм үткәрергә;

- хокукый актлар чыгару инициативасын тәкъдим итүне яклап имзалар җыю буенча инициатив төркемнәр булдыру;

- район халкы имзаларын җыю һәм законга каршы килми торган ысуллар белән хокукый актлар чыгару инициативасын яклау буенча агитация алып бару.

4. Районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары район халкына хокукый актлар чыгару инициативасын тормышка ашыруда ярдәм итәргә тиеш.

5. Гражданнарның хокукый актлар чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты әлеге Устав белән билгеләнгән компетенцияләре нигезендә ул кертелгән көннән өч ай эчендә район Советы тарафыннан аның ачык утырышында, Район Башлыгы яки район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан мәҗбүри карап тикшерелергә тиеш.

6. Гражданнарның хокукый актлар чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проектын карау процедурасы район Советы регламенты, район Башлыгының, район Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

**19 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә**

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан-туры халык тарафыннан гражданнарның җыелышлар һәм конференцияләре уздыру, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнары булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яши торган түбәндәге территорияләре чикләрендә гамәлгә ашырыла ала: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булып тормаган авыл торак пункты; муниципаль район чикләрендә гражданнарның башка яшәү территорияләре.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре Биектау муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча Биектау муниципаль районы Советы раслый торган территориаль иҗтимагый үзидарә турындагы Нигезләмәдә каралган тәртиптә билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә аның уставы нигезендә юридик зат була ала һәм коммерциячел булмаган оешманың оештыру-хокукый формасында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында билгеләнә:

1) ул гамәлгә ашырыла торган территория;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләрен формалаштыру, туктату, хокуклары һәм бурычлары, вәкаләтләре срогы;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук күрсәтелгән мөлкәт һәм финанс

чараларыннан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруны туктату тәртибе.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы, әгәр анда территориядә уналты яшькә җиткән яшәүчеләрнең өчтән береннән дә ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе, әгәр анда тиешле территориядә уналты яше тулган яшәүчеләрнең кимендә өчтән берен тәшкил итүче гражданнар җыелышларында сайланган делегатларның кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышы, конференциясенең аерым вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәр һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрен кайгырталар;

2) гражданнар җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр;

3) территорияне карап тоту, төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген, күрсәтелгән гражданнар акчалары исәбеннән дә, район Башкарма комитеты белән килешү нигезендә район бюджеты акчаларын файдаланып та тормышка ашыра алалар;

4) күрсәтелгән актларны кабул итү алар компетенциясенә кертелгән җирле үзидарә органнарына, әлеге органнар һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары мәҗбүри карарга тиешле муниципаль норматив хокукый актлар проектларын кертергә хокуклы.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе, җирле бюджеттан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе әлеге Устав һәм район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

## 20 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә кую тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне булдыру максатларында район халкы, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территориаль иҗтимагый үзидарә уставы проектын эшләүне гамәлгә ашыручы һәм чикләрендә шушы территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территориядә яшәүче гражданнар җыелышын чакыруны оештыручы гражданнарның инициатив төркеме

төзелә.

2. Гражданнар җыелышы район территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында карар кабул итә, аның уставын кабул итә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү белән бәйле мәсьәләләр буенча район Советында гражданнар җыелышын күрсәтергә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) билгели.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә район Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәгән вакыттан бирле гамәлгә куелган дип санала.

## 21 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен гражданнар җыелышы вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) тарафыннан район Башлыгына тапшырыла:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында гражданнар җыелышының барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган гариза;

2) вәкаләтле һәр вәкилнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын һәм бирелү датасын, яшәү урыны адресын күрсәтеп территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында карар кабул ителгән гражданнар җыелышы беркетмәсе;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы ике нөсхәдә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән документлардан тыш, башка документларны тапшыру турындагы таләп рөхсәт ителми.

Вәкаләтле вәкилгә документлар алу турында, аларны алу исемлеген һәм датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

3. Район Башлыгы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турындагы документлар кергән көннән алып ике атна вакыт эчендә аны Район Советының уставны теркәү турындагы яки аны теркәүдән баш тарту турындагы карар проектын алдан карауны һәм әзерләүне оештыра.

4. Гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкилләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставын алдан караганда һәм Район Советы утырышында киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хокуклы.

5. Район Советы территориаль иҗтимагый-үзидарә уставын теркәү турында яки әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар Район Башлыгы тарафыннан алынганнан соң 30 көн эчендә аны теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә. Уставны теркәүдән баш тарту дәлилле булырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту өчен нигез булып территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нормалары Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Уставка, башка муниципаль норматив хокукый актларга каршы килүе тора.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарәне төзүнең максатка ярашлы булмавы мотивлары буенча территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту рөхсәт ителми.

8. Район Советы тарафыннан кабул ителгән территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү мәсьәләсе буенча дәлилләнгән карар өч көн эчендә рәсми рәвештә гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) игътибарына җиткерелергә тиеш.

9. Район Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында Карар кабул ителгән очракта уставның бер нөсхәсе аны теркәү турында тамгасы белән гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхәсе район Советында саклана.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставына кертелә торган үзгәрешләр район Советы тарафыннан әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш. Күрсәтелгән үзгәрешләр аларны теркәү көненнән үз көченә керә.

**22 статья. Гавами тыңлаулар, иҗттимагый фикер алышулар**

1. Муниципаль берәмлек Советы катнашында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу өчен муниципаль берәмлек Башлыгы тарафыннан гавами тыңлаулар үткәрелергә мөмкин.

2. Гавами тыңлаулар халык инициативасы белән, муниципаль берәмлек Советы, муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан үткәрелә.

Халык яисә муниципаль берәмлек Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Совет тарафыннан билгеләнә, ә муниципаль берәмлек башлыгы яисә контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма комитет җитәкчесе инициативасы буенча - муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Гавами тыңлауларга мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) муниципаль район уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, муниципаль район уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе (уставы), законнарына муниципаль район уставын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;

4) муниципаль районны үзгәртеп кору мәсьәләләре, муниципаль районны үзгәртеп кору өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13 статьясы нигезендә тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән муниципаль район халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.

3. Проектлар буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе муниципаль район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә һәм муниципаль район халкына гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан ук таныштыруны, муниципаль район халкының гавами тыңлауларында катнашуны, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, гавами тыңлауларның

нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә торган башка чараларны күздә тотарга тиеш.

4. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проетлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирләрдән файдалануның һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда, мондый файдалануның башка төренә үзгәрешләр кертү турында карарлар проектлары буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль район вәкиллекле органының кыскартылган исеме норматив хокукый акт белән билгеләнә торган иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрелә.

**23 статья. Гражданнар җыелышы**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, районның җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларының эшчәнлеге турында халыкка мәгълүмат бирү өчен район территориясендә гражданнар җыелышы үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыелышлары микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар, районның торак пунктлары буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыелышы халык, район Советы, район Башлыгы инициативасы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда үткәрелә.

3. Район Советы яки район Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар җыелышы тиешенчә район Советы яки район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы белән уздырыла торган гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, тиешле территориядә яшәүче һәм җыелышта катнашу хокукына ия халык саныннан кимендә 10 процентыннан ким булмаган санлы гражданнар төркеменең, шушы территорияләрдә урнашкан предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренең язма тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимдә аны карауга чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеге, җыелышны уздыру вакыты һәм урыны күрсәтелергә тиеш. Тәкъдимгә вәкаләтле затлар имза салырга тиеш, ә җыелышны үткәрү инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итсә - фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, аларның һәркайсының яшәү урыны адресын күрсәтеп, әлеге гражданнар тарафыннан имзалана.

Район Советы үзенең якын киләчәктәге сессиясендә гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимне карый.

Район Советы гражданнарның җыелышын үткәрүдән анық максатка ярашлы түгеллеге мотивлары буенча баш тартырга хокуклы түгел.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышын уздыру вакыты һәм урыны һәм фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләр җыелыш үткәрелгәнгә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә, моның өчен массакүләм мәгълүмат чаралары, почта хәбәрләре, фатир (йорт) саен әйләнүләр, белдерүләр һәм башка мөмкин булган чаралар кулланыла. Гражданнар җыелышын әзерләү һәм уздыруны район Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашу хокукы булган гражданнарның гомуми саны муниципаль сайлаулар уздырганда файдаланыла торган Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу күрсәткечләре нигезендә билгеләнә.

Җыелышта катнашу хокукына ия гражданнар санының кимендә өчтән бере катнашса, гражданнар җыелышы тулы хокуклы дип санала.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

8. Гражданнар җыелышы районның җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итәргә, шулай ук районның җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле затларны сайларга мөмкин.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча үткәрелә торган гражданнар җыелышы анық компетенциясенә территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

10. Гражданнар җыелышы кабул иткән мөрәҗәгатьләр компетенцияләренә мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне хәл итү кертелгән районның җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан язма җавап җибәрелеп һичшиксез каралырга тиеш.

11. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм уздыру тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль закон, әлеге Устав һәм район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

12. Гражданнар җыелышы йомгаклары рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**24 статья. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)**

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм район халкының фикерен ачыклау зарурлыгы очрагында уздырыла. Район территориясендә яшәүче кешеләр арасыннан гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышын чакыру кыенлашкан очракларда уздырыла.

2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышын) билгеләү һәм үткәрү, делегатлар сайлау тәртибе әлеге Устав һәм (яисә) район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, район Советы, район Башлыгы инициативасы белән уздырыла. Район Советы яки район Башлыгы инициативасы белән уздырыла торган гражданнар конференциясе район Советы яки район Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык инициативасы белән уздырыла торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) район Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), әгәр анда сайланган делегатларның яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышлары) карарлары конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе, әгәр анда уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләрнең кимендә өчтән берен тәшкил итүче гражданнар җыелышларында сайланган делегатларның кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

6. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) нәтиҗәләре рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**25 статья. Гражданнарны сораштыру**

1. Гражданнардан сораштыру җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен бөтен территориядә яисә район территориясендә үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре рекомендация бирү характерында.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия район халкы катнашырга хокуклы.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәгеләр инициативасы буенча үткәрелә:

1) район Советы яки район Башлыгы-җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары - республика һәм төбәкара әһәмияттәге объектлар өчен Район җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнар фикерен исәпкә алу өчен.

4. Гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм үткәрү тәртибе район Советының уставы яисә норматив хокукый акты белән билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турындагы карар район Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында район Советы карарында билгеләнә:

1) сораштыруны үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителә торган) мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы район халкының минималь саны.

6. Район халкы гражданнардан сораштыру үткәрү турында аны үткәрүгә кимендә 10 көн кала хәбәр ителә.

7. Гражданнарны сораштыруны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чараларны финанслау гамәлгә ашырыла:

1) Район бюджеты хисабына-район җирле үзидарә органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән-Татарстан Республикасы дәүләт хакимия-те органнары инициативасы буенча сораштыру уздырганда.

8. Сораштыру нәтиҗәләре аны уздырганнан соң бер ай эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән районның теләсә кайсы кешесе танышырга хокуклы. Районның җирле үзидарә органнары тиешле карарлар кабул иткәндә сораштыру нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

## 26 статья. Гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләре

1. Гражданнар районның җирле үзидарә органнарына индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләргә хокуклы.

2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль закон һәм 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## 27 статья. Район халкы тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруның һәм аны гамәлгә ашыруда катнашуның башка формалары

1. Федераль закон нигезендә җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруның һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуының әлеге уставта каралган формалары белән беррәттән гражданнар Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формаларда җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашырга хокуклы.

2. Район халкы тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры тормышка ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы законлылык, иреклелек принципларына нигезләнә.

Җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарә вазыйфаи затлары халыкка җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруда һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуында ярдәм итәргә тиеш.

## III Бүлек. РАЙОН СОВЕТЫ

### 28 статья. Район Советы - районның вәкиллекле җирле үзидарә органы

1. Район Советы районның даими эшләүче сайлаулы коллегиаль вәкиллекле җирле үзидарә органы булып тора.

2. Район Советының рәсми исеме – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы».

3. Район Советы вәкаләтләре срогы - 5 ел.

4. Район Советы район халкы алдында хисап тота һәм аның контролендә.

5. Район Советы юридик зат хокукларына ия, мөһере, штампы, тиешле символикалы бланкы, банкта исәп-хисап счеты бар.

6. Район Советы эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

### 29 статья. Район Советы составы

1. Район Советы 50 депутаттан тора.

2. Район Советы аның составына депутатларның кимендә өчтән икесе район Советының билгеләнгән саныннан сайланганда хокуклы була

### 30 статья. Район Советы депутатларын сайлау тәртибе

1. Район Советы составына район составына керүче җирлекләр башлыклары һәм күрсәтелгән җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары, җирлек халкы санына бәйсез рәвештә, һәр җирлектән бер вәкил күләмендә вәкиллек нормасы нигезендә җирлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан үз составыннан сайланган депутатлар керә.

Муниципаль район составына керүче бер җирлекнең вәкиллеге нормасы район Советының билгеләнгән санының өчтән береннән арта алмый.

2. Җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан сайлана торган район Советы депутаты яңа чакырылыш тиешле җирлекнең вәкиллекле органының тулы хокуклы составында беренче сессия көненнән бер айдан да соңга калмыйча сайланырга тиеш, шул исәптән әлеге чакырылыш органы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта да.

3. Район Советы депутатын җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан сайлап алу яшерен тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла һәм күрсәтелгән орган карары белән рәсмиләштерелә.

4. Җирлек Башлыгын сайлау һәм җирлекнең вәкиллекле органы депутатын район Советы депутаты итеп сайлау турындагы карар өч көн эчендә район Советына җибәрелә.

### 31 статья. Район Советы депутаты статусы

1. Район депутаты вәкаләтләре аны җирлек башлыгы яисә җирлекнең

вәкиллекле органы депутатлары арасыннан район Советы депутаты итеп сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш район Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

2. Район Советы депутаты, әлеге Устав билгеләгән очраклардан тыш, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм хезмәт вазыйфаларын башкару белән берләштереп, азат ителмәгән нигездә эшли.

3. Район Советы депутаты 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга тиеш.

4. Район Советы депутатына законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары нигезендә үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.

5. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды территорияләрендә, аларны үткәрү тормыш-яшәешне тәэмин итү объектлары, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә эшчәнлеге, җәяүлеләр һәм (яисә) транспорт чаралары хәрәкәте, яисә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт, яисә социаль инфраструктура объектларына үтеп керү мөмкинлеге бозылмау шартларында уздырыла. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына мондый очрашулар турында хәбәр итү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны уздыру датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

6. Җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.

7. Депутатның гавами чара рәвешендә сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә.

8. Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнә торган гавами чара рәвешендә депутатның сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә уздыруга каршылык күрсәтү Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка китерә.

9. Район Советы депутаты район Советы раслаган депутатның түбәндәге йөкләмәләрен үз эченә алырга тиешле Депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш:

1) шәхсән үзенең яисә якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарәнең башка органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусын файдаланмаска;

2) депутат бурычларын объектив башкаруда шик тудырырлык үз-үзеңне тотыштан тыелырга, шулай ук аның абруена яисә район Советы абруена зыян китерергә сәләтле конфликтлы хәлләрдән тайпылырга;

3) мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү куркынычы булганда - шәхси кызыксыну депутат бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган ситуация - бу хакта район Советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге конфликтны булдырмауга яисә җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) район Советында билгеләнгән гавами чыгышлар кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне фаш итмәскә һәм файдаланмаска;

6) депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссуда, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) алмаска.

10. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты хокуксыз:

1) шәхсән үзе яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә (сәяси партия белән, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәр итеп катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) идарә органнарында һәм гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциясез хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

11. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны башкарырга тиеш. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм (кертемнәр) кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган, әгәр башкасы әлеге Федераль закон белән каралган булмаса, чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, вазыйфаларны башкармаган очракларда депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

12. Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турында законнары нигезендә депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан тәкъдим ителә торган керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылган мәгълуматларының дөреслеге һәм тулы булуын тикшерү Татарстан Республикасы иң югары вазыйфаи затының (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча Татарстан Республикасы законы билгеләгән тәртиптә үткәрелә.

12. Әлеге статьяның 6.2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны сакламау һәм вазифаларын үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы иң югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутатның, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасының, җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында җирле үзидарәнең тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле органына яки судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

13. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирелә.

14. Район Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлгән очракта;

2) үз теләге буенча отставкага киткәндә;

3) суд тарафыннан гамәл кылуга яраксыз яки гамәл кылуга чикле яраклы дип табылса;

4) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип танылса яки үлгән дип табылса;

5) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керсә;

6) Россия Федерациясе чикләреннән читкә даими яшәргә китсә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит ил - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы - гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы чит дәүләт органнарына сайланырга, аларга чит дәүләт гражданлыгы алырга яки яшәүгә рөхсәт алу яисә Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документ яисә башка документ алу хокукына ия, аның нигезендә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;

8) сайлаучылар тарафыннан район составына керүче җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак чакыртып алыну;

9) район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки аның вәкаләтләрен җирлек башлыгы яисә җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә алынса;

11) федераль законнар белән билгеләнгән башка очракларда.

15. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта, депутат, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.
(Биектау районы Советының 28.09.2016 N 86 карары редакциясендә)

16. Тиешле җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, күрсәтелгән орган бер ай эчендә район Советы составына башка депутатны сайларга тиеш.

**32 статья. Район Советы депутатының район халкы белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Район Советы депутаты район халкы белән, шулай ук район территориясендә урнашкан предприятие, оешма, дәүләт органнары һәм башка органнар коллективлары

белән элемтәдә тора.

2. Район Советы депутаты үзе вәкил булган җирлек халкы алдында хисап тота, үз эше турында, район Советы эше хакында аларга даими мәгълүмат биреп тора, шулай ук халыкны кабул итә.

3. Район Советы депутаты район халкының законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чараларны күрергә, шул исәптән алардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, аларда булган мәсьәләләрне дөрес һәм үз вакытында хәл итәргә булышырга тиеш.

**33 статья. Яңа сайланган район Советы эшен оештыру**

1. Яңа чакырылыш район Советы беренче сессиягә район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе сайланган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча җыела. Сайлаулардан соң район Советы утырышын район Башлыгы, ул булмаганда район Башлыгы Урынбасары чакыра һәм әзерли.

2. Район Башлыгын сайлаганчы, район Советының беренче сессиясен районның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара.

**34 статья. Район Советының компетенциясе**

Район Советы компетенциясенә керәләр:

1) муниципаль берәмлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) җирле бюджетны һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау;

3) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

4) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;

5) муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибен билгеләү;

6) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә тарифлар билгеләү, эшләр башкару турында, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

7) муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында муниципаль берәмлекнең катнашу тәртибен билгеләү;

8) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

9) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәвен контрольдә тоту;

10) депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлауларны билгеләү;

11) үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча регламент һәм башка хокукый актлар кабул итү;

12) муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую;

13) муниципаль берәмлек башлыгын отставкага чыгару турында карар кабул

итү;

14) Биектау муниципаль районының рәсми символларын билгеләү;

15) җирле үзидарәнең вәкиллекле органы һәм ул төзи торган органнарның структурасын һәм штатларын раслау;

16) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программалар раслау;

17) чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору турында инициатива белән чыгу;

18) җирле референдумны билгеләү;

19) район Башлыгын сайлау;

20) район Башлыгы урынбасарын сайлау;

21) район Башкарма комитеты Җитәкчесен, Финанс-бюджет палатасы Рәисен, Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисен билгеләп кую, аларның отставкасын кабул итү;

22) район Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү;

23) район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен билгеләү, конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

24) Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәне, Финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәне һәм Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәне раслау;

25) чикләрне үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне билгеләү;

26) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

27) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә тарифлар билгеләү, эшләр башкару турында, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

28) районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

29) муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында районның катнашу тәртибен билгеләү;

30) җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен контрольдә тоту;

31) районны территориаль планлаштыру документларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә башка шәһәр төзелеше документларын раслау;

32) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның җирле резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибен билгеләү;

33) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү өчен район бюджетыннан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

34) үз массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую;

35) район Уставы һәм район Советы карарлары аңлату;

36) автоном коммерциясез оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерциясез оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

37) район Советы аппараты турындагы нигезләмәне раслау;

38) район Башлыгын отставкага чыгару турында карар кабул итү;

39) районның Контроль-хисап палатасы рәисен һәм әгъзаларын (аудиторларны) каралган тәртиптә билгеләп кую;

40) район Советының режимлы-яшерен бүлекчәсен булдыру, аның хезмәткәрләренең санын билгеләү;

41) муниципаль район территориясендә үз компетенциясе чикләрендә хәрби идарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә оборона өлкәсендәге законнарның үтәлешен тәэмин итү;

42) район Советының мобилизацион әзерлек органы аша эшчәнлеге күрсәтелгән органнар эшчәнлегенә бәйле яисә аларны алып бару өлкәсендәге район җирле үзидарә органнарын һәм оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыру, тәэмин итү һәм җитәкчелек итү;

43) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль районнарның вәкиллекле органнарын алып баруга кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав белән район Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләр.

2. Район Советы район Башлыгының, Башкарма комитет Җитәкчесенең эшчәнлекләре нәтиҗәләре, Башкарма комитет һәм район Башлыгының ведомство буйсынуындагы башка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән район Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык отчетларын тыңлый.

**35 статья. Район Советының эш тәртибе**

1. Район Советының эш тәртибе әлеге Устав һәм Район Советы Регламенты белән билгеләнә.

2. Район Советы эшенең төп формасы булып аның район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итә торган утырышлары тора.

3. Әгәр район Советы утырышында район Советының сайланган депутатлары санының 50 проценттан ким булмаган өлеше катнашса, ул тулы хокуклы була.

4. Район Советының чираттагы утырышлары зарурлык туган саен үткәрелә, әмма өч айга бер тапкырдан ким булмаганча уздырыла. Чираттан тыш утырышлар район Башлыгы яки район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бере инициативасы белән чакырыла.

5. Совет утырышлары район Башлыгы тарафыннан чакырыла. Район Советы депутатлары һәм чакырылган затлар чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырышка - аны үткәрүгә бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6. Район Советының һәр утырышында беркетмә алып барыла. Беркетмәгә сессияне уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы белешмәләр кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр санап үтелә һәм, тавыш бирү йомгакларын күрсәтеп, кабул ителгән барлык карарлар теркәлә. Район Башлыгы Беркетмәгә кул куйганнан соң белән районның теләсә кайсы кешесе танышырга мөмкин.

7. Район Советы утырышында һәр депутат бер тавышка ия. Район Советы депутаты шәхсән үзе тавыш бирү хокукын гамәлгә ашыра. Район Советы утырышында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемләп) һәм яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Устав, район Советы регламенты белән билгеләнә.

### 36 статья. Район Советы эшчәнлеген оештыру

1. Район Советы эшчәнлеген район Башлыгы оештыра.

2. Район Советы регламенты нигезендә район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен депутатлар арасыннан, район Башлыгы һәм аның урынбасарларыннан тыш, район Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими комиссияләр төзелә, шулай ук вакытлы комиссияләр төзелергә мөмкин.

3. Муниципаль программаларны, район Советы карарлары проектларын әзерләү, район карамагына кертелгән мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен район Советы каршында депутатлар, район Башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм район халкы составындагы эшче, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре оештырылырга мөмкин.

4. Район Советы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка төрле тәэмин итү район Советы аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### 37 статья. Район Советының контроль функцияләрен гамәлгә ашыруы

1. Район Советы район территориясендә әлеге Уставның район Советы кабул итә торган нигезләмәләренең үтәлешен, район бюджетының үтәлешен, бюджеттан тыш фондлар акчаларыннан, районны үстерү программаларыннан файдалануны, район Башкарма комитеты һәм аның Җитәкчесе эшчәнлеген контрольдә тота.

2. Районның җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан законнарны, әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны бозу фактлары ачыкланган очракта, район Советы, район Башлыгы карары белән, күрсәтелгән фактларны тикшерү өчен депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләре төзелергә мөмкин.

3. Законнар нигезендә район Советы, район Башлыгы карары белән район бюджеты акчаларыннан максатчан файдалануны, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген, шулай ук район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык эшчәнлегенең башка мәсьәләләрен тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелергә мөмкин. Тикшерүләр (ревизияләр) үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә бәйсез аудиторлар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре җәлеп ителә ала.

4. Район Башкарма комитеты, аның Җитәкчесе, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазыйфаи затлар, әгәр закон белән башкасы билгеләнмәсә, район Советы, аның контроль комиссияләре, район Советы депутаты мөрәҗәгате буенча район Советы карамагына караган мәсьәләләр буенча соратылган мәгълүмат бирергә, ә законнар, муниципаль норматив хокукый актлар бозылган очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Район Советы, контроль функцияләрен башкарганда, район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкарма-күрсәтмә эшчәнлегенә катнашырга

хокуклы түгел.

**38 статья. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Район Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) район Советы тарафыннан үзтаратылу турында карар кабул итү;

2) район Советы депутатларының әлеге составының хокуксызлыгы турында Татарстан Республикасы Югары суды карары үз көченә кергән очракта, шул исәптән депутатлар үз вәкаләтләрен туктатуга бәйле рәвештә дә;

3) 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3, 3.2, 4 - 6, 6.1, 6.2, 7.1, 7.2, өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта;

4) район чикләре үзгәрү нәтиҗәсендә район сайлаучылары саны 25 проценттан артыкка күбәйгән очракта;

5) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогы бозылган очракта.

2. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Район Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлекләрнең вәкиллекле органнары бер ай дәвамында район Советы составына башка депутатларны сайларга тиеш.

**39 статья. Район Советының үзтарату турында карар кабул итү тәртибе**

1. Район Советының үзтарату турындагы карары район Башлыгы яки район Советы депутатларының билгеләнгән санының кимендә яртысы күләмендә депутатлар төркеме инициативасы буенча кабул ителергә мөмкин.

2. Үзтарату турында карар кабул итү инициативасы тәкъдим ителә алмый:

1) район Советы сайланганнан соң беренче ел дәвамында;

2) район бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисап раслау чорында;

3) район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа район Башлыгын сайлаганчы.

3. Район Советын үзтарату турында язма тәкъдим үзтарату мотивларын үз эченә алырга тиеш, шулай ук аңа үзтарату сәбәпләре нигезләнгән башка төр материаллар да беркетелергә мөмкин.

4. Үзтарату турында мәсьәләне алдан карау өчен район Советы карары белән депутатлар арасыннан комиссия төзелә. Район Советы яки район Башлыгы карары нигезендә район Советын үзтарату мәсьәләсе гавами тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Район Советын үзтарату мәсьәләсен карау дәвамлылыгы район Советы

депутатлары һәм район халкы тарафыннан үзтарату инициативасының барлык хәлләре һәм дәлилләрен һәрьяклап һәм объектив карау мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үзтарату турында карар үзтарату турында инициатива чыгарылган көннән соң ике ай узып кабул ителергә мөмкин.

6. Район Советын үзтарату турында карар яшерен тавыш бирү юлы белән район Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

7. Район Советы үзтарату турында тәкъдимнәр кире кагылган очракта, үзтарату турындагы кабат инициатива, үзтарату турындагы мәсьәлә буенча тавыш биргән көннән кимендә бер елдан соң чыгарылырга мөмкин.

**40 статья. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Район Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлгән очракта;

2) үз теләге буенча отставкага киткәндә;

3) суд тарафыннан гамәл кылуга яраксыз яки гамәл кылуга чикле яраклы дип табылса;

4) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип танылса яки үлгән дип табылса;

5) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керсә;

6) Россия Федерациясе чикләреннән читкә даими яшәргә китсә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит ил - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы чит дәүләт органнарына сайланырга, аларга чит дәүләт гражданлыгы алырга яки яшәүгә рөхсәт алу яисә Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ яисә башка документ алу хокукына ия, аның нигезендә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;

8) сайлаучылар тарафыннан район составына керүче җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак чакыртып алу;

9) район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки аның вәкаләтләрен җирлек Башлыгы яисә җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә алынса;

11) әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда башкасы каралмаган булса, депутат тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле

әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, вазыйфаларны башкармау;

12) федераль законнар белән билгеләнгән башка очракларда.

2. 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

3. Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында район Советы карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, ә бу нигез район Советы утырышлары арасында барлыкка килгән очракта, - шундый нигез барлыкка килгән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

4. Тиешле җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, күрсәтелгән орган бер ай эчендә район Советы составына башка депутатны сайларга тиеш.

5. Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн - әлеге гаризаның район Советына кергән көне була.

## IV бүлек. РАЙОН БАШЛЫГЫ

### 41 статья. Район Башлыгы –районның иң югары вазыйфаи заты

1. Район Башлыгы районның иң югары вазыйфаи заты булып тора.

2. Район Башлыгы район Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара. Район Башлыгы булып сайланган район Советы депутатының вәкаләтләре туктатыла.

3. Район Башлыгы вазыйфасының рәсми атамасы - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы». Район Башлыгы вазыйфасының кыскартылган исеме - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы».

### 42 статья. Район Башлыгын сайлау тәртибе

1. Район Башлыгы район Советы депутатлары арасыннан яңа сайланган муниципаль район Советының беренче сессиясендә яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана, әгәр район Советы вәкаләтләре срогына район Советы тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә.

Район Башлыгын сайлау район Советы депутатлары тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән район халкының, иҗтимагый берләшмәләрнең, Татарстан Республикасы Президентының тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Район Советы депутаты район Башлыгы булып район Советы

депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, сайланган булып санала.

3. Сайланганнан соң, Район башлыгы түбәндәге ант китерә:

«Муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешкәндә, - миңа муниципаль берәмлек Уставы белән бирелгән үз вәкаләтләремне гамәлгә ашырганда, бүгенге һәм киләчәк буыннар алдында муниципаль берәмлек өчен җаваплылыкны аңлап, Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, муниципаль берәмлек Уставын катгый үтәргә, муниципаль берәмлек халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итәргә, тарихи традицияләрне ихтирам итеп, гражданлык ризалыгына һәм икътисадый потенциалны арттыруга омтылырга, муниципаль берәмлекнең чәчәк атуы өчен һәм аның барлык халкы бәхете хакына үз вазыйфаларымны намуслы үтәргә ант итәм».

**43 статья. Район Башлыгы статусы**

1. Район Башлыгы даими нигездә эшли.

2. Район Башлыгы үз эшчәнлегендә федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә район Советы һәм район халкы контрольлегендә һәм алар алдында хисап тота.

3. Район башлыгы үзенең эшчәнлеге турында район Советы алдында елга кимендә бер тапкыр хисап тота.

4. Район Башлыгы «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны башкарырга тиеш.

5. Район Башлыгы түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) шәхсән үзе яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә (сәяси партия белән, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел

профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы иң югары вазыйфаи затына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) идарә органнарында һәм гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциясез хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

Район Башлыгы гражданлык яки җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.

Район Башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав белән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

**44 статья. Район Башлыгы вәкаләтләре**

Район Башлыгы:

1) районны башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә, Җирлек исеменнән ышанычнамәсез эш итә;

2) район Советы эшен оештыра, район Советы сессиясен чакыра һәм аларда рәислек итә;

3) әлеге Устав билгеләгән тәртиптә район Советы кабул иткән норматив хокукый актларга кул куя һәм халыкка җиткерә;

4) үз вәкаләтләре чикләрендә район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре

буенча хокукый актлар чыгара;

5) район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт төзи;

6) район Советы эшендә ачыклыкны һәм җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны тәэмин итү чараларын күрә;

7) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) район Советы сессияләре беркетмәләренә имза сала;

9) район Советы аппараты эше белән җитәкчелек итә;

10) район Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны координацияли;

11) район Советын карап тоту һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен район бюджетында каралган чыгымнар буенча эш итүче булып тора;

12) закон һәм әлеге Устав нигезендә гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча район Советының хокукый актын кабул итүне оештыра;

13) район җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән район территориясендә гамәлдә булган хезмәттәшлеген тәэмин итә;

14) район исеменнән икътисадый һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек турында дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек итү һәм гамәлләрне координацияләү турында килешүләр төзи;

15) муниципаль хезмәткәрләрнең һәм районның җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү күләмнәрен һәм шартларын билгели;

16) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

17) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге исеменнән чыгыш ясый;

18) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гавами партнер булса яки «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге катнашында уртак конкурс үткәрү планлаштырылса (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очрактан тыш), муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итә, шулай ук 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив-хокукый актлары, әлеге Устав һәм муниципаль

хокукый актлар белән каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

19) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлеше нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органын билгели.

20) Район Башлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына муниципаль-хосусый партнерлык проектын аның нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру һәм 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясындагы 2-5 өлешләре нигезендә аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен җибәрә.

21) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль районнар Башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Устав, район Советы карарлары белән район башлыгы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

### 45 статья. Район Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу очраклары:

1) үлеме;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага җибәрү;

4) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан баш тарту;

5) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә өлешчә сәләтсез дип танылуы;

6) суд тарафыннан хәбәрсез юк булуы яки үлгән дип хәбәр ителүе;

7) судның аңа карата булган гаепләү хөкем карарының законлы көченә керүе;

8) даими яшәү өчен Россия Федерациясе чикләреннән чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу, Россия Федерациясе халыкара килешүендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, әлеге килешү нигезендә чит ил гражданины җирле үзидарә органнарына сайланырга, Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе белән халыкара килешүдә катнашмаган чит ил территориясендә яшәргә хокуклы икәнен дәлилләүче, чит ил гражданины гражданлыгы алырга, тору өчен рөхсәт яки башка төр документ алырга хокуклы, шуның белән бәйле рәвештә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданины җирле үзидарә органнарына сайлана алу хокукына ия;

10) җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

11) 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә

җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3, 3.2, 4 - 6, 6.1, 6.2, 7.1, 7.2, өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта;

12) район чикләре үзгәрү нәтиҗәсендә район сайлаучылары саны 25 проценттан артыкка күбәйгән очракта;

13) сәламәтлеге торышы буенча суд тәртибендә район башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсез дип билгеләнгән;

14) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогы бозылган очракта;

15) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-10, 13-15 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, районның яңа Башлыгын сайлау район Советының якындагы утырышында гамәлгә ашырыла.

3. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча сак астына алу рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерелгән очракта, яңа сайланган район Башлыгы вазыйфасына керешкәнче, аның вәкаләтләрен вакытлыча район Башлыгы урынбасары башкара.

Район Башлыгы урынбасары билгеләнмәгән яисә булмаган очракта күрсәтелгән вәкаләтләрне җирле үзидарәнең вазыйфаи заты яисә район Советы тарафыннан билгеләнгән муниципаль район Советы депутаты башкара.

4. Район Башлыгы, аның хатыны һәм балигъ булмаган балалары 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законда билгеләнгән тыюларны үтәмәү очрагында район Башлыгы вәкаләтләре Россия Федерациясе Президенты ышанычын югалтуга бәйле рәвештә шулай ук вакытыннан алда туктатыла;

муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль район Башлыгына карата тиешенчә муниципаль район Башлыгы сайлауларында күрсәтелгән затлар кандидатлар буларак теркәлгән чорда Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану факты билгеләнү.

5. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, муниципаль сайлауларда сайлана торган район Башлыгын сайлаулар 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда билгеләнгән срокларда уздырыла.

6. Әгәр вәкаләтләре Татарстан Республикасы югары вазыйфаи затының (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенең) район Башлыгы вазыйфасыннан баш тарту турында яки район Советы карары нигезендә район Башлыгын отставкага чыгару турындагы хокукый акты нигезендә вакытыннан алда туктатылган район Башлыгы әлеге хокукый актларга яисә карарга суд тәртибендә шикаять биргән очракта, муниципаль сайлауларда сайлана торган район Башлыгын вакытыннан алда сайлаулар суд карары закон көченә кергәнче билгеләнеп куела алмый.

**46 статья. Район Башлыгы урынбасары**

1. Район Башлыгы тәкъдиме белән район Башлыгы урынбасары депутатлар арасыннан сайлана.

2. Район Советы депутаты, район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыгы аны хуплап тавыш бирсә, район Башлыгының сайланган урынбасары булып санала.

3. Район Башлыгы урынбасары район Советы регламентында билгеләнгән вазыйфаларны бүлү нигезендә функцияләр үти, район Башлыгының йөкләмәләрен үти, ә вакытлыча (авыруга яисә отпускка бәйле) ул булмаган яисә үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаган яисә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта район Башлыгы вазыйфаларын башкара.

4. Район Башлыгы район Советына азат ителгән нигездә бер урынбасарны сайларга тәкъдим итәргә хокуклы.

5. Район Башлыгы урынбасарының вәкаләтләре әлеге Уставның 40 статьясында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла.

6. Район Башлыгы урынбасары статусына бәйле башка чикләүләр федераль законнарда билгеләнгән.

7. Район Башлыгы урынбасары үз вазыйфасыннан район Советы инициативасы белән яки депутатлар төркеме таләбе буенча район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бере күләмендә теләсә кайсы вакытта чакыртып алынырга мөмкин. Район Башлыгы урынбасарын чакыртып алу турындагы карар район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

8. Даими нигездә эшләүче район Башлыгы урынбасары хокуксыз:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә (сәяси

партия белән, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) Татарстан Республикасы законы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы иң югары вазыйфаи затына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп катнашу;

в) Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) идарә органнарында һәм гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциясез хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

Район Башлыгы урынбасары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

9. Район Башлыгы урынбасары 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә һәм бурычларны башкарырга тиеш.

## V бүлек. РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### 47 статья. Район Башкарма комитеты - район җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы

1. Район Башкарма комитеты район җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы булып тора.

2. Район Башкарма комитеты район Советын, район Башлыгы һәм район халкы

контролендә һәм аның алдында хисап тота.

3. Район Башкарма комитеты юридик зат хокукларына ия.

4. Район Башкарма комитетын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе җитәкли, ул аның белән берүзе идарә итү принципларында җитәкчелек итә.

5. Район Башкарма комитетының рәсми исеме - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль казна учреждениесе», кыскартылган исеме - «Район Башкарма комитеты».

6. Район Башкарма комитеты мөһергә, район гербы төшерелгән һәм үз исеме белән бланкларга, шулай ук гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен Башкарма комитетка тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, Россия Федерациясенең гербы төшерелгән түгәрәк мөһергә ия.

7. Район Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

**48 статья. Район Башкарма комитеты структурасы**

1. Башкарма комитет структурасы район Советы тарафыннан Башкарма комитеты Җитәкчесе тәкъдиме буенча раслана.

2. Район Башкарма комитеты структурасына Башкарма комитет Җитәкчесе, аның урынбасарлары, тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары керә. Башкарма комитетның район Башкарма комитеты аппаратына кермәгән структур бүлекчәләре мөстәкыйль юридик затлар була ала.

3. Район Башкарма комитетының структур бүлекчәләре район Советы раслаган нигезләмә нигезендә эш итә.

4. Район Башкарма комитеты эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, аның компетенциясенә кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне килешеп хәл итү өчен Районның Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән Башкарма комитет каршында координацион, эксперт һәм башка киңәшү (консультатив) органнар төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән органнар Район Башкарма комитеты структурасына керми. Аларда эш җәмәгать тәртибендә гамәлгә ашырыла.

**49 статья. Район Башкарма комитеты вәкаләтләре**

Район Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм хисап өлкәсендә:

- район бюджеты проектын (бюджет проектын һәм урта сроклы финанс планын) төзүне тәэмин итә;

- кирәкле документлар һәм материаллар белән район бюджеты проектын (бюджет проекты һәм урта сроклы финанс планы) район Советы раславына кертә;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бюджетара трансфертларны бүлү методикасын һәм (яисә) бирү тәртибен эшли һәм раслый;

- район бюджетының үтәлешен һәм бюджет хисабын төзүне тәэмин итә, район Советы раславына район бюджетының үтәлеше турында хисап тапшыра;

- муниципаль бурыч белән идарә итүне тәэмин итә;

- район социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектын эшләүне тәэмин итә;

- район бюджетын үтәүне, районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен үтәүне оештыра;

-район икътисады һәм социаль өлкәсе торышын чагылдыра торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыра һәм әлеге күрсәткечләрне дәүләт хакимияте органнарына законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшыра;

- җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәләрен район бюджеты акчалары исәбеннән тигезләүне тәэмин итә;

- район Советы карарлары нигезендә муниципаль кыймммәтле кәгазьләр чыгару, кредитлар алу, муниципаль гарантияләр бирү юлы белән муниципаль бурыч алуны гамәлгә ашыра һәм муниципаль мөлкәтне закладка сала;

2) муниципаль милек белән идарә итү, район территориясендә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- районның муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итә, муниципаль милек объектларын булдыру, сатып алу, файдалану, идарә итү һәм арендалау буенча мәсьәләләрне хәл итә (әгәр башкасы район Советы карары белән билгеләнмәгән булса);

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, муниципаль предприятие һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә һәм муниципаль предприятие һәм учреждениеләр тарафыннан башкарылучы эшләр тарифларны раслый, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаса, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүне һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль бурычларны үтәүне финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны тәэмин итә;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән районның икътисадый һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында килешүләр төзи; район территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр төзүгә ярдәм итә;

- районның хезмәт күрсәтүче административ участогында полициянең участок уполномоченные вазыйфасын биләгән хезмәткәргә эш өчен бина тапшыра;

- 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полициянең участок уполномоченные вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан әлеге вазифаи бурычларны үтәгән чорга торак бина тәкъдим итә;

3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә:

- районның территориаль планлаштыру документлары проектларын, башка шәһәр төзелеше документларын әзерли һәм район Советына раслауга кертә һәм аларның тормышка ашырылуын тәэмин итә;

- район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча мәгълүмат системаларын алып баруны, муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлау һәм алуны гамәлгә ашыра;

-әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чараларны

оештыра;

- Биектау муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлек оештыруда катнаша;

- район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортлар төзи, үстерә һәм саклауны тәэмин итә, җирле әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрне файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

- муниципаль урман контролен гамәлгә ашыра;

- район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә, федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрә;

- муниципаль районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра;

- 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны һәм территориянең планынраслауны оештыра;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итә, район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра һәм район чикләрендә авыл җирлекләре арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруны тәэмин итә;

- район чикләрендә торак пунктлар арасында халыкка хезмәт күрсәтүче җәмәгать транспорты маршрутларын, хәрәкәт графикларын, тукталышлары урыннарын раслый яки килештерә;

- район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җәмәгать транспорты тукталышлары өчен бирелгән урыннарны төзекләндерүне тәэмин итә;

- район составына керүче җирлекләрне элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- адреслау объектларына адреслар бирүне, адреслар үзгәртүне, юкка чыгаруны, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирүне, муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирүне, мондый исемнәрне үзгәртүне, гамәлдән чыгаруны, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыруны тәэмин итә;

5) торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә, шулай ук төзекләндерү һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә:

-энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программалар раслый һәм гамәлгә ашыра, күпфатирлы йортларны, район

чикләрендә муниципаль торак фондын тәшкил итүче биналарны энергетик тикшерүне оештыра, энергияне сак тоту турындагы һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чараларны оештыра һәм үткәрә;

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итүне оештыра;

- муниципаль район составына керүче җирлекләрне җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- җирлекара китапханәләр белән халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне, китапханә фондларын туплауны һәм аларның саклануышын тәэмин итүне оештыра;

- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра һәм җирлекара күмү урыннарын карап тотуны тәэмин итә;

- район составына керүче җирлекләрдә җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыра;

- район составына керүче җирлекләрне ял итүне оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләрен күрсәтү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә;

- җирлекләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыра, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итә, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм иреклеләргә (добровольчество) ярдәм итә;

- район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсешен тәэмин итә, районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары үткәрүне оештыра;

- 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законда каралган җылылык белән тәэмин итүне оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы «Су белән тәэмин итү һәм су үткәрү турында» Федераль законда каралган су белән тәэмин итү һәм су үткәрү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» Федераль законда каралган стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- реклама конструкцияләрен урнаштыру схемаларын раслый, муниципаль район территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирә, мондый рөхсәтләрне гамәлдән чыгара, муниципаль район территориясендә 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган үз белдеге белән куелган реклама конструкцияләрен сүтү турында күрсәтмәләр бирә;

6) мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә:

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруны оештыра, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыра (финанс ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары гамәлгә ашырган

балаларны өстәмә укытудан тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү, балаларны карау өчен шартлар тудыра, шулай ук үз вәкаләтләре чикләрендә, аларның тормыш һәм сәламәтлек иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

- муниципаль мәгариф оешмалары биналарын һәм корылмаларын карап тотуны, аларга якын территорияләрне төзекләндерүне тәэмин итә;

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балалар исәбен алып бара, муниципаль белем бирү оешмаларын районның конкрет территорияләренә беркетә;

- муниципаль белем бирү оешмаларын төзи, яңадан оештыра, юкка чыгара (муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан югары белем бирүче муниципаль белем бирү оешмалары төзелүдән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен (халкы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган аерым территорияләрнең халыкны медик-санитар тәэмин итү буенча функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләр исемлегенә кертелгән җирлекләр территорияләреннән тыш) гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә шартлар тудыра;

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра;

- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, район Советы депутатларына, муниципаль хезмәткәрләргә һәм учреждениеләр хезмәткәрләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыра;

- 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

- район территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яисә арбитраж судта, җирле үзидарә хокукларын бозучы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт вазыйфаи затлары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар актларына шикаять бирә;

- муниципаль милиция тарафыннан җәмәгать тәртибен саклауны оештыруны тәэмин итә;

- район территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүдә катнаша;

-территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм район территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә; гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның җирле резервларын булдыруны тәэмин итә;

- район территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

- үз вәкаләтләре чикләрендә һәм билгеләнгән тәртиптә халыкка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә килеп чыгу куркынычы турында вакытында хәбәр итүне һәм халыкка мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

- су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- җирле референдумны әзерләү һәм уздыруны, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

- үз вәкаләтләре чикләрендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук район территориясендә терроризм һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча чаралар күрүне тәэмин итә;

- район чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыра;

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен яклауга һәм үстерүгә, җирле аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

- терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү өлкәсендә муниципаль программалар эшлиләр һәм гамәлгә ашыралар;

- муниципаль берәмлекләрдә терроризмның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда терроризм идеологиясен кабул итмәү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эше һәм башка чаралар үткәрү юлы белән, мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә;

- федераль башкарма хакимияте органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган терроризмны профилактикалау, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча чараларда катнаша;

- муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыкка каршы яклануга таләпләрне үтәүне тәэмин итәләр;

- терроризмны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тәкъдимнәр җибәрә;

- терроризмны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар;

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән район җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен

гамәлгә ашыра;

- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс чараларының исәбен алып бара һәм тиешле куллануны тәэмин итә;

- федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра;

- район Советы карарлары нигезендә аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен район җирле үзидарә органнары карамагындагы матди ресурслар һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә;

- Россия Федерациясенең су законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлар өчен гомуми файдаланудагы су объектларын файдалану кагыйдәләрен билгели, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә;

9) оборона, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендә:

- муниципаль район территориясендә үз компетенциясе чикләрендә хәрби идарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә оборона өлкәсендәге законнарның үтәлешен тәэмин итү;

- эшчәнлекләре күрсәтелгән органнар эшчәнлегенә бәйле яисә аларны алып бару өлкәсендә булган район җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның мобилизацион әзерлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларга җитәкчелек итү;

10) башка вәкаләтләр:

- муниципаль хезмәтләр реестрын төзү һәм алып бару тәртибен билгели;

- җирлекләрнең архив фондларын саклауны да кертеп, муниципаль архивны формалаштыра һәм карап тота;

- үз вәкаләтләре чикләрендә федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;

- законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары белән район Советы, район Башлыгы яки башка җирле үзидарә органнары компетенцияләренә кертелгән вәкаләтләрдән тыш, районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Башкарма комитет районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль район музейларын төзи;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнаша;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлек гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

4) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм муниципаль район территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм итә;

5) 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагындагы югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен башкара;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтә;

8) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре төзегән оешмаларга 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон нигезендә ярдәм күрсәтә;

9) 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыра;

10) «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законның 31.1 һәм 31.3 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтә;

11) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыра;

12) инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культурасын һәм адаптив спортын үстерүгә ярдәм итү.

3. Район Башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль өлкәсендә район Башкарма комитеты вәкаләтләренә керәләр:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контроль нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү, аны уздыру күрсәткечләре һәм методикасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана;

5) федераль законнарда, законнарда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру буенча функцияләр, мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә, район Башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләрне оештыру һәм уздыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

**50 статья. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе әлеге вазыйфага контракт буенча билгеләнә торган район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булып тора.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе үз вәкаләтләрен даими нигездә башкара.

3. Аерым оештыру-күрсәтмә функцияләрен башкару өчен район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарларга ия. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вакытлыча булмаганда (авыруга яисә отпускка бәйле рәвештә) яисә үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаганда, я вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, аның вәкаләтләрен район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарларының берсе билгеләнгән вазифаларны бүлү нигезендә башкара.

5. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә һәм бурычларны башкарырга тиеш.

**51 статья. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү тәртибе**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе билгеләү конкурс нигезендә үткәрелә.

Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе район Советы тарафыннан билгеләнә. Конкурсны уздыру тәртибе конкурс уздыру көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча конкурс шартлары, аны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында белешмәләрне, контракт проектын бастырып чыгаруны күздә тотарга тиеш.

2. Конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны район Советы тарафыннан билгеләнә.

Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы - район Советы, ә икенче яртысы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

3. Зат конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан район Советы тарафыннан район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына билгеләп кую турындагы карар район башлыгы тәкъдиме буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан район Советы утырышында депутатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

4. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе өчен контракт шартлары район Советы тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә һәм Татарстан Республикасы законы белән җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә раслана.

5. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт район Башлыгы тарафыннан төзелә.

6. Контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе:

1) Район Советы контролендә һәм аның алдында хисап тота;

2) Район Советына үз эшчәнлеге һәм Башкарма комитет эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Район Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисапларны тапшыра;

3) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен хәл итү буенча Район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

**52 статья. Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләре срогы**

1. Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына зат билгеләү турында карар кабул иткән район Советы вәкаләтләре чорына, ләкин ике елдан ким булмаган вакытка төзелә (яңа чакырылыш район Советы эшли башлаган көнгә кадәр).

2. Район Советы вәкаләтләре срогы чыккач, район Башкарма комитеты Җитәкчесе үз вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә район Башкарма комитетының яңа Җитәкчесе билгеләнгәнче гамәлгә ашыруын дәвам итә.

**53 статья. Башкарма комитет Җитәкчесе вәкаләтләре**

Башкарма комитет Җитәкчесе:

1) район Башкарма комитетының эшчәнлеге белән берүзе идарә итү принципларында җитәкчелек итә һәм үз компетенциясенә керүче район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне үтәү өчен шәхси җаваплылык тота;

2) район Советы, район Башлыгы, районның һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә районның Башкарма комитетын тәкъдим итә;

3) район Советы каравына район бюджеты проектларын һәм аның үтәлеше турындагы хисапларны тәкъдим итә;

4) муниципаль районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проектын һәм аның үтәлеше турында хисап тапшыра;

5) Башкарма комитет структурасы проектын район Советы раславына кертә, хезмәткәрләрнең иң чик саны һәм хезмәт өчен түләү фонды билгеләгән структура нигезендә район Башкарма комитетының штат расписаниесен раслый;

6) район Башлыгы белән килештереп Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарларын билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм район башкарма комитетының башка хезмәткәрләрен вазыйфасына билгеләп куя, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

7) үз вәкаләтләре чикләрендә расланган бюджет нигезендә район чаралары белән эш итә;

8) район Башкарма комитеты тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан

Республикасы законнары белән район җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруны гамәлгә ашыра һәм (яисә) тәэмин итә, аларны үтәү өчен шәхси җаваплылыкка ия; тиешле законнар нигезендә һәм үтәү йөзеннән тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара;

9) район Башкарма комитеты компетенциясенә кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча хокукый актлар, шулай ук район Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

10) район Башлыгы, район Советы таләбе буенча яки елга бер тапкырдан да ким булмаганча үз эшчәнлеге һәм район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында район Советына хисап тапшыра;

11) район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими рәвештә хәбәр итә, район Башкарма комитеты хезмәткәрләре гражданнарны кабул итә, айга кимендә бер тапкыр гражданнарны кабул итә, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

12) дәүләт һәм башка органнарда район мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, район Башкарма комитеты исеменнән судка гариза бирә, ышанычнамәләр тапшыра;

13) район Советы раславына район Башкарма комитеты органнары турындагы нигезләмәләр проектларын тәкъдим итә;

14) район Башкарма комитеты органнары җитәкчеләрен район Советы билгеләгән тәртиптә вазыйфасына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә;

15) законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары һәм төзелгән контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**54 статья. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлеме;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 37 статьясының 11 яисә 11.1 өлеше нигезендә яклар килешүе буенча контрактны өзү яисә суд тәртибендә;

4) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан читләштерү;

5) суд тарафыннан гамәлләр кылуга яраксыз яки чикле яраклы дип тану;

6) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип тану яки үлгән дип табылса;

7) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керсә;

8) Россия Федерациясе чикләреннән читкә даими яшәргә китсә;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит ил - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит

ил гражданы чит дәүләт органнарына сайланырга, аларга чит дәүләт гражданлыгы алырга яки яшәүгә рөхсәт алу яисә Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы булып тормаган чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ яисә башка документ алу хокукына ия, аның нигезендә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;

10) хәрби хезмәткә чакыру яки аны алыштыра торган альтернатив гражданлык хезмәтенә җибәрелү;

11) 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3, 3.2, 4 - 6, 6.1, 6.2, 7.1, 7.2, өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта;

(Биектау район Советының 26.05.2017 N 145 карары редакциясендә 11 п.)

12) район чикләре үзгәрү нәтиҗәсендә район сайлаучылары саны 25 проценттан артыкка күбәйгән очракта;

13) гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогы бозылган очракта;

14) Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вәкаләтләрен башкаручы район Башлыгы вазыйфасына керешү.

2. Башкарма комитет Җитәкчесе белән контракт яклар килешүе буенча яисә суд тәртибендә түбәндәгеләрнең гаризасы нигезендә өзелергә мөмкин:

1) Район Советының яисә район Башлыгының - җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 37 статьясының 9 өлешендә билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;

2) Татарстан Республикасы Президентының - контракт шартларын җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештә, шулай ук законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә;

3) Башкарма комитет Җитәкчесенең - җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан контракт шартлары бозылуга бәйле рәвештә.

3. Башкарма комитет Җитәкчесе белән контракт законнар нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә ачыкланган 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе

территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законда билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны сакламау һәм вазифаларын үтәмәве ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты гаризасы нигезендә суд тәртибендә өзелә ала.

4. Башкарма комитет Җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча аны сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүриләү чаралары кулланылган очракта, район Башкарма комитетының яңа Җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәнче, район Советы карары белән билгеләнгән район Башкарма комитеты Җитәкчесенең урынбасарларының берсе яисә вәкаләтле муниципаль хезмәткәр башкара.

## VI бүлек. РАЙОН СОВЕТЫ, РАЙОН БАШЛЫГЫ ҺӘМ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

### 55 статья. Район Советы, Район Башлыгы һәм Башкарма комитетының үзара хезмәттәшлеге нигезләре

1. Әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү нигезендә район Советы, район Башлыгы һәм Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль гамәлгә ашыра.

2. Район Советы һәм Район Башкарма комитеты районның икътисадый һәм социаль үсеше процесслары белән нәтиҗәле идарә итү максатларында законнарда, әлеге Устав белән билгеләнгән формалары белән үзара хезмәттәшлек итәргә тиеш.

3. Район Советы һәм Район Башкарма комитеты кабул ителгән хокукый актларны кул куелган көннән алып җиде көн эчендә бер-берсенә юллыйлар.

4. Район Советы, район Башлыгы Район Башкарма комитеты җитәкчесенә Район Башкарма комитеты җитәкчесенең, Район Башкарма комитетының башка вазыйфаи затларының хокукый актларын кабул итү, юкка чыгару, үзгәртү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

5. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе район Советына, район Башлыгына район Советының, район Башлыгының хокукый актларын кабул итү, юкка чыгару, үзгәртү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

6. Район Башлыгы район Башкарма комитеты Җитәкчесенә район Советының эш планнарын һәм район Советы карарлары проектларын район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә юллый.

7. Район Советы утырышларында, аның органнары утырышларында, район Башлыгы үткәрә торган утырышларда киңәш бирү тавышы хокукы белән район Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның урынбасарлары яки вәкаләтле затлар катнашырга хокуклы. Язма чакыру булган очракта, район Башкарма комитетының вазыйфаи затлары район Советы утырышында катнашырга бурычлы.

8. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе үткәрә торган утырышларда район Башлыгы, район Советы депутатлары катнашырга хокуклы.

### 56 статья. Район җирле үзидарә органнары арасында бәхәсләрне хәл итү

Район җирле үзидарә органнары арасында аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр килештерү процедураларын үткәрү юлы белән яки суд тәртибендә хәл ителә.

## VII бүлек. РАЙОН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕНЕҢ БАШКА ОРГАННАРЫ

### 57 статья. Районның Контроль-хисап палатасы

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе район Советы оештыра торган тышкы муниципаль финанс контроленең даими эшләүче органы.

Районның Контроль-хисап палатасы оештыру һәм функциональ бәйсезлеккә ия һәм үз эшчәнлеген мөстәкыйль башкара.

2. Районның Контроль-хисап палатасы район Советы алдында хисап тота.

3. Район Контроль-хисап палатасы вәкаләтләре, составы, оештыру һәм эшчәнлеге тәртибе «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә район Советы карары белән билгеләнә.

Районның Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасы муниципаль вазыйфа булып тора.

4. Районның Контроль-хисап палатасы Рәисе үз вазыйфасына район Советы тарафыннан билгеләнә. Районның Контроль-хисап палатасы Рәисенең вәкаләтләр чоры - алты ел.

Районның Контроль-хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатуралар турындагы тәкъдимнәр район Советына кертелә:

- район Башлыгы тарафыннан;
- район Советы депутатлары тарафыннан - район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере тарафыннан.

Районның Контроль-хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү һәм күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау тәртибе район Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Районның Контроль-хисап палатасы Рәисе вазыйфасын биләүгә бәйле чикләүләр, шулай ук аның статусы гарантияләре федераль законнар белән билгеләнә.

6. Районның Контроль-хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) район бюджеты үтәлешен контрольдә тоту;
2) район бюджеты проектларына экспертиза;
3) район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү;
4) район бюджеты акчаларын, шулай ук район бюджеты тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган башка чыганаклардан алына торган акчаларны файдалануның законлылыгын, нәтиҗәлелеген (эффективлыгы һәм экономиялеген)

контрольдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

5) муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлекнең саклanuчы нәтиҗәләре һәм районныкы булган индивидуальләштерү чараларына карата билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тору;

6) район бюджеты акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләрне, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук муниципаль гарантияләр бирүнең һәм йөкләмәләрне юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан район бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган алыш-бирешләр буенча башка ысуллар белән үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) муниципаль хокукый актлар проектларына (финанс-икътисадый нигезләрнең нигезле булуын да кертеп) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләренә, шулай ук муниципаль программаларга кагылышлы өлешендә финанс-икътисадый экспертиза;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессын анализлау һәм аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләү;

9) район бюджетын үтәү барышы турында, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм мондый мәгълүматны район Советына һәм район Башлыгына тапшыру;

10) коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләре чикләрендә катнашу;

11) район составына керүче җирлекләр бюджетларына кергән район бюджеты акчаларын файдалануның законлылыгын, нәтиҗәлелеген (эффективлыгы һәм экономиялелеген) контрольдә тоту;

12) район составына керүче җирлекләрдә, район Советы тарафыннан җирлекләр советлары белән төзелгән килешүләр нигезендә, тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру;

13) районның чыгым йөкләмәләре реестрындагы белешмәләрнең чыгым йөкләмәләре реестрына кертелгән районның чыгым йөкләмәләре һәм район бюджеты проекты нигезендә чираттагы финанс елында финанслауга планлаштырыла торган чыгым йөкләмәләре арасында тәңгәллекне ачыклау предметына анализ;

14) программаларны һәм районның үсеш планнарын гамәлгә ашыруның барышына һәм нәтиҗәләренә контроль;

15) район бюджеты үтәлешенә мониторинг;

16) райондагы социаль-икътисадый хәлгә анализ;

17) районның җирле үзидарә органнарында эчке финанс контролен оештыруга ярдәм итү;

18) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта һәм район Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендәге башка вәкаләтләр.

7. Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла торган тикшерүләрнең нәтиҗәләре район Советы утырышында тикшерелергә, шулай ук рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

8. Районның Контроль-хисап палатасы юридик зат хокукларына ия, үз исеме белән герблы мөһере һәм район гербы төшерелгән бланклары бар.

**58 статья. Районның Финанс-бюджет палатасы**

1. Район Финанс-бюджет палатасы муниципаль-казна учреждениесе районның эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы даими эшләүче финанс органы булып тора. Районның Финанс-бюджет палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- район бюджеты проектын (бюджет проекты һәм уртача сроклы финанс планы) төзи;

- район Советы раславына кертү өчен кирәкле документлар һәм материаллар белән район бюджеты проектын (бюджет проектын һәм уртача сроклы финанс планын) район Башкарма комитетына тәкъдим итә;

- район бюджетын үтәүне оештыра;

- җирле үзидарә финанс органының Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән һәм (яисә) аның нигезендә кабул ителә торган район муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бүтән бюджет вәкаләтләре.

2. Җирле үзидарәнең финанс органы вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда районның Финанс-бюджет палатасы район Башкарма комитеты алдында хисап тота.

3. Районның Финанс-бюджет палатасы үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм район Советы раслаган Финанс-бюджет палатасы турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

Районның Финанс-бюджет палатасы Рәисе муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча район Советы тарафыннан билгеләнә. Районның Финанс-бюджет палатасы Рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан билгеләнә.

4. Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булып тора, районның финанс органы эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

5. Районның Финанс-бюджет палатасының район гербы сурәтләнгән һәм үз исеме белән мөһере һәм бланклары бар.

6. Районның Финанс-бюджет палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

**59 статья. Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы**

1. Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль-казна учреждениесе районның түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы даими эшләүче җирле үзидарә органы булып тора:

- районның муниципаль милкендәге, шул исәптән район милкендәге җир кишәрлекләре, акцияләр, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларындагы өлешләр (кертемнәр) белән идарә итә, муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, алардан файдалану, идарә итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- район Советы карары белән билгеләнә торган очракларда муниципаль

милекне аерып алу турында, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәрне район Советына килештерүгә (раслауга) әзерли һәм кертә;

- район муниципаль милкендәге җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыра һәм оештыра;

- район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре төзү өчен кирәкле эшләрне башкаруны, 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы «Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ия булуга ачык аукцион уздыруны тәэмин итә;

- район территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләре кулланыла;

- муниципаль мөлкәт реестрын Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән тәртиптә алып бара.

Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда районның Башкарма комитеты алдында хисап тота.

2. Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы район авыл җирлекләре территорияләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

- авыл җирлекләре ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны, 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы «Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ия булуга ачык аукцион уздыруны тәэмин итә.

3. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм район Советы раслый торган Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

4. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе район Советы тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

5. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булып тора, Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

6. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының район гербы сурәтләнгән һәм үз исеме белән мөһере һәм бланклары бар.

7. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## VIII бүлек. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

### 60 статья. Район сайлау комиссиясе

1. Район сайлау комиссиясе муниципаль сайлаулар, җирле референдум, депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын чакыртып алу, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм үткәрүне оештыра.

2. Район сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган.

3. Район сайлау комиссиясе район Советы тарафыннан федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

Район Сайлау комиссиясе түбәндәгеләрнең тәкъдиме нигезендә төзелә: Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр, шулай ук район Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре; башка сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр; яшәү, эшләү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышлары; район сайлау комиссиясенең алдагы составы; Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе.

4. Район Советы түбәндәгеләрдән кергән тәкъдимнәр нигезендә район сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан яртысын билгеләп куярга тиеш:

1) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең;

3) район Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренең.

5. Район Советы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кергән тәкъдимнәре нигезендә район сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысын билгеләп куярга тиеш.

6. Район сайлау комиссиясе вәкаләтләре срогы биш ел тәшкил итә.

7. Районның сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия 8 әгъза составында төзелә.

8. Район сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

9. Район сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән җайга салына. Район Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан

Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча район сайлау комиссиясе вәкаләтләре территория сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

## IX бүлек. РАЙОН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК-ХОКУКЫЙ ҺӘМ ФИНАНС ЭШЧӘНЛЕГЕ НИГЕЗЛӘРЕ

### 61 статья. Юридик зат хокукларына ия булган Район җирле үзидарә органнары

1. Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә юридик зат хокукларына район Советы, район Башкарма комитеты, районның Финанс-бюджет палатасы, районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы һәм районның Контроль-хисап палатасы ия.

2. Район Советы карары белән юридик зат хокуклары башка муниципаль органнарга, шулай ук район Башкарма комитеты структурасы нигезендә аның аерым органнарына бирелергә мөмкин.

### 62 статья. Районның җирле үзидарә органнары юридик затлар буларак

1. Район исеменнән мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычлар сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәсез чыгыш ясарга район Башкарма комитеты Җитәкчесе мөмкин.

2. Район Башлыгы мөлкәти һәм башка хокукларны һәм бурычларны ала һәм гамәлгә ашыра, район Советы, район Башлыгы, депутатлар эшчәнлеген тәэмин итүгә юллана торган район бюджеты акчалары белән, шулай ук район Советына беркетелгән муниципаль мөлкәт белән эш итүгә бәйле рәвештә, судта ышанычнамәсез чыгыш ясый.

3. Юридик зат хокукларына ия районның җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен төзелә торган муниципаль казна учреждениеләре булып тора һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик затлар буларак дәүләт теркәве узарга тиеш.

### 63 статья. Районның җирле үзидарә органнарын финанслау

1. Районның җирле үзидарә органнарын тоту чыгымнары район бюджетының үз керемнәре исәбеннән финанслана.

2. Законда, әлеге Уставта, район Советы карарлары белән каралган очракларда районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджеты чыгымнарын классификацияләү нигезендә аерым юл белән карала.

## X бүлек. РАЙОН БАШЛЫГЫНЫҢ ҺӘМ БАШКА МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРНЫҢ СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ГАРАНТИЯЛӘРЕ

### 64 статья. Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә

**ашыручы депутатына, сайланулы вазыйфаи затына бирелә торган гарантияләр**

1. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына муниципаль район бюджеты акчалары исәбеннән гарантияләнә:

1) муниципаль район җирле үзидарә органнарының хокукый актлары нигезендә вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итә торган эш шартлары;

2) үз вакытында һәм тулы күләмдә акчалата түләү алу;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү белән тәэмин ителә торган, ял көннәрен һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрен, шулай ук ел саен бирелә торган түләүле ял бирү;

4) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын һәм аларның гаилә әгъзаларын, шул исәптән депутат, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты пенсиягә чыккач медицина ярдәме белән тәэмин итү;

5) тиешле еллар эшләгән өчен пенсия белән тәэмин итү һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә депутат, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вафат булган очракта гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү;

6) депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының алар вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук алар муниципаль вазыйфаларны биләгән чорда яисә аны туктатканнан соң хезмәткә сәләтлелеген югалткан очракта, әмма алар үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән очракта, аның сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян салыну очрагына иминиятләштерү.

2. Әлеге статьяның беренче өлешендәге 4 - 6 пунктларында каралган гарантияләр даими нигездә депутат, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы затларга һәм бу чорда пенсия яшенә җиткән яисә хезмәткә сәләтлелеген югалткан затларга кагыла һәм күрсәтелгән затларның вәкаләтләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 35 статьясындагы 16 өлешенең җиденче абзацында, 6 өлешенең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 36 статьясындагы 6.1 өлешендә, 40 статьясындагы 7.1 өлешендә, 10 өлешнең 5-8 пунктларында,10.1 өлешендә, 73 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләрдә туктатылган очракта кулланылмый.

3. Район Башлыгына һәм аның урынбасарларына, даими нигездә эшләүче район Советы депутатларына, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

4. Әлеге статьяда билгеләнгән гарантияләрне бирү тәртибе район Советы карары белән билгеләнә.

**65 статья. Район Башлыгы, район Советы депутатларының кагылгысызлыгы гарантияләре**

1. Район Советы депутатлары, район Башлыгы хокуклары гарантияләре

җинаять яки административ җаваплылыкка тарту, тоткарлау, кулга алу, тентү, сорау алу, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль эшләр башкару, шулай ук үзләре биләгән торак һәм (яки) хезмәт урыны, аларның багажы, шәхси һәм хезмәт транспорт чараларына, язышуларына, алар кулланган элемтә чараларына, аларның документларына карата оператив-эзләү чараларын уздырганда, федераль законнар белән билгеләнә.

2. Федераль закон нигезендә район Советы депутаты, район Башлыгы әйткән фикерләре, тавыш биргәндәге позицияләре һәм аларның статусына туры килә торган башка гамәлләре, шул исәптән вәкаләтләр чоры тәмамланганнан соң да, җинаять яки административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә район Советы депутаты, район Башлыгы тарафыннан җибәрелгән халык алдында кимсетүләр, яла ягу яки федераль закон белән алар өчен җаваплылык каралган башка хокук бозу очракларына кагылмый.

## XI бүлек. РАЙОН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

### 66 статья. Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары район халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында федераль законнар нигезендә җаваплы.

### 67 статья. Район Советы депутатларының район халкы алдында җаваплылыгы

1. Район Советы депутатларының, шул исәптән район Башлыгының, район халкы алдында җаваплылыгы депутат итеп аны сайлаган район халкының ышанычын югалту нәтиҗәсендә барлыкка килә.

2. Ышанычны югалткан район Советы депутаты, шул исәптән район Башлыгы, җирлекнең вәкиллекле органы депутаты буларак, федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә кире чакыртып алынырга мөмкин.

### 68 статья. Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының дәүләт алдында җаваплылыгы

Федераль закон нигезендә район Советының, район Башлыгының, район Башкарма комитеты Җитәкчесенең дәүләт алдында җаваплылыгы алар тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Устав бозылган очракта, шулай ук районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырмау очрагында тиешле суд карары нигезендә барлыкка килә.

### 69 статья. Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының

**физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы**

Район җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә барлыкка килә.

**70 статья. Ышанычны югалтуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән азат итү (вазыйфадан азат итү)**

1. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә муниципаль вазыйфа биләүче зат ышанычны югалтуга бәйле рәвештә түбәндәге очракларда эштән азат ителергә (вазыйфадан азат ителергә) тиеш:

1) зат тарафыннан үзе барлыкка китергән мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар кабул ителмәү;

2) зат тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырылмаган яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат бирелгән;

3) федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, затның коммерция оешмасының идарә органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашуы;

4) затның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруы;

5) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, затның идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керүе.

2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль вазыйфаны биләүче зат ышанычын югалтуга бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан яклар аңа буйсынган зат булган мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чараларын күрмәгән очракта.

1. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә муниципаль вазыйфа биләүче зат ышанычны югалтуга бәйле рәвештә түбәндәге очракларда эштән азат ителергә (вазыйфадан азат ителергә) тиеш:

1) зат тарафыннан үзе барлыкка китергән мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар кабул ителмәү;

2) зат тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырылмаган яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат бирелгән;

3) федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, затның коммерция оешмасының идарә органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашуы;

4) затның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруы;

5) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, затның идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керүе.

2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль вазыйфаны биләүче зат ышанычын югалтуга бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан яклар аңа буйсынган зат булган мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чараларын күрмәгән очракта.

3. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары күрелергә мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

4) вәкаләтләр чоры туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

## XII бүлек. РАЙОННЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

### 71 статья. Районның муниципаль хокукый актлары системасы

1. Районның муниципаль хокукый актлары системасына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль берәмлек уставы, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар;

2) муниципаль берәмлек Советының норматив һәм башка хокукый актлары;

3) әлеге уставта каралган муниципаль берәмлек башлыгының, Башкарма комитет җитәкчесенең һәм җирле үзидарәнең башка органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының хокукый актлары.

2. Район уставы һәм җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул

ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар муниципаль хокукый актлар системасында югары юридик көч актлары булып тора, турыдан-туры гамәлдә була һәм районның бөтен территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актларга каршы килмәскә тиеш.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар районның бөтен территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш.

4. Муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен гражданнар, оешма җитәкчеләре, дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затлары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары федераль законнар һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә җаваплы булалар.

5. Районның муниципаль хокукый актлары, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә торган салымнар һәм җыемнар турында район Советының норматив хокукый актларыннан тыш, әлеге Устав билгеләгән тәртиптә үз көченә керә.

6. Районның муниципаль хокукый актлары Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килмәскә тиеш.

7. Муниципаль хокукый актлар юкка чыгарылырга яисә аларның гамәлдә булуы муниципаль хокукый актны гамәлдән чыгару яисә туктатып тору вакытына тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан, мондый органнар яисә тиешле вазыйфалар бетерелгән очракта яки күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затларның - җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының вәкаләтләре исемлеге үзгәргән очракта, муниципаль хокукый актның гамәлдә булуын туктатып тору вакытына тиешле муниципаль хокукый актны, шулай ук суд тарафыннан кабул итү (бастырып чыгару) кертелгән; ә җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала торган өлешендә - Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы) тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

8. Норматив характердагы булмаган муниципаль хокукый актның гамәли көче аны кабул иткән (чыгарган) район җирле үзидарә органы яисә район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең тиешле күрсәтмәсен алган очракта кичекмәстән туктатылып тора. Алынган күрсәтмәнең үтәлеше турында район Башкарма комитеты яисә районның җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә өч көн эчендә, ә район Советына - карар кабул ителгән көннән

алып өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

9. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы башка муниципаль берәмлекләрнең муниципаль норматив хокукый актлары, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә экспертиза узарга мөмкин.

**72 статья. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры район халкы тарафыннан хәл итү җирле референдумда чагылган гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр район халкын турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль норматив хокукый акт кабул итү таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү кергән район җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 15 көн эчендә тиешле муниципаль норматив хокукый актны әзерләү һәм кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан арта алмый.

3. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу район Башлыгын чакыртып алу, район Башкарма комитеты Җитәкчесенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.

**73 статья. Район җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары кабул итә торган муниципаль хокукый актларның төрләре**

1. Район җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән түбәндәге муниципаль хокукый актлар чыгаралар:

1) район Советы - район Советы карарлары;

2) район Башлыгы - район Башлыгының карарлары һәм күрсәтмәләре;

3) район Башкарма комитеты Җитәкчесе - Башкарма комитет Җитәкчесе карарлары һәм күрсәтмәләре.

2. Район җирле үзидарәсенең башка вазыйфаи затлары әлеге Устав, аларның статусын билгеләүче башка муниципаль хокукый актларда билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә күрсәтмәләр һәм боерыклар чыгара.

**74 статья. Муниципаль хокукый актларны әзерләү**

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары район Башлыгы, район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты Җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, шулай ук районның

Контроль-хисап палатасы, районның Финанс-бюджет палатасы, районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан аларны алып бару мәсьәләләре буенча кертелергә мөмкин.

Биектау муниципаль районы прокуроры, гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү кирәклеген үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында билгеләгәндә, муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, бетерү яисә кабул итү турындагы проектлар һәм тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

2. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе, аларга теркәлә торган документларның исемлеге һәм формасы тиешенчә район Советы, район Башлыгы, район Башкарма комитеты Җитәкчесе регламентында билгеләнә.

3. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган башка муниципаль берәмлекләрнең муниципаль хокукый актлары проектлары тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә җайга салу йогынтысы бәяләнергә мөмкин, моңа түбәндәгеләр керми:

1) муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы норматив хокукый актлар проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектлары.

**75 статья. Район Советының хокукый актлары**

1. Район Советы үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча район территориясендә үтәлүе мәҗбүри булган кагыйдәләр, район Башлыгын отставкага чыгару турында карар, район Советы регламенты, район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча башка карарлар, шулай ук федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав тарафыннан үз компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

2. Район Советы карарлары, законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Район Башлыгы тавышы район Советы карарларын кабул иткәндә депутат тавышы буларак исәпкә алына.

4. Советның җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм бетерүне, район бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тотучы карарлары, район Советы каравына бары тик район Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы белән яисә аның бәяләмәсе булганда кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән бәяләмә район Башкарма комитетына карар проектын тәкъдим иткән көннән алып утыз көн эчендә район Советына тапшырыла.

5. Район Советы карарларына район Башлыгы тарафыннан алар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә имзалана һәм әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелә.

## 76 статья. Район Башлыгының хокукый актлары

Район башлыгы үзенең законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар, шулай ук әлеге Устав, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, башка федераль законнар белән аның компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара.

## 77 статья. Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең хокукый актлары

Башкарма комитет Җитәкчесе район Башкарма комитетының законнарда, әлеге Уставта һәм район Советы карарларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм районның җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар, шулай ук район Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгара.

## 78 статья. Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Район Советы карарлары, әгәр карарның үзе белән башкасы билгеләнмәгән булса, район Башлыгы имза куйган көннән үз көченә керә.

Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Район Советының район Уставын кабул итү яисә әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карарлары федераль закон, әлеге Устав билгеләгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Район Башлыгының, Башкарма комитет Җитәкчесенең, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр актларның үзләре тарафыннан башкасы билгеләнмәсә, алар имзаланган көннән үз көчләренә керә.

3. Гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң басма массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет-ресурсында pravo.tatarstan.ru (алга таба текст буенча - бастырып чыгару) яисә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелгәннән соң (алга таба текст буенча –халыкка җиткерелү) үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, имза салу датасы (район Советы кабул иткән хокукый актлар өчен - шулай ук аны район Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актка кул куйган вазыйфаи затның исеме булырга тиеш.

5. Район Советының район бюджеты, аның үтәлеше турындагы, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турындагы карарлары, район Советы, район Башлыгы, район Башкарма комитеты Җитәкчесе кабул иткән башка норматив хокукый актлар, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, имза салынган көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Җирле референдумны билгеләү, районның чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору, район Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау, район Башкарма комитеты Җитәкчесен һәм аның урынбасарларын билгеләп кую мәсьәләләре буенча норматив булмаган хокукый актлар шулай ук рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми басылып чыгуы (халыкка җиткерелүе) мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган район җирле үзидарәсе органнары яисә вазыйфаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) мөмкин.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

Муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару хокукый акт текстын районның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган басма массакүләм мәгълүмат чараларында яки район территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашырыла. Хокукый акт текстын башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы турында тамга булырга тиеш.

Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- хокукый акт текстын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында районның рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру;

- хокукый акт текстын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру.

9. Муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) массакүләм мәгълүмат чарасы чыгу датасы күрсәтелергә тиеш.

10. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар, Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## XIII бүлек. РАЙОННЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЕ

### 79 статья. Районның икътисадый нигезе

Районның икътисадый нигезен районның муниципаль милкендәге мөлкәт, район бюджеты акчалары, шулай ук районның мөлкәти хокуклары тәшкил итә.

## 80 статья. Районның муниципаль мөлкәте

1. Дәүләт милкеннән муниципаль район милкенә тапшырылган, шулай ук башка законлы нигезләрдә сатып алынган мөлкәт муниципаль районның милке булып тора.

2. Муниципаль районның муниципаль милкендә булырга мөмкин:

1) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) җирле үзидарә органнары, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән хәл итү хокукы бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 4 өлеше нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә каралган мөлкәт, шулай ук 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга каралган мөлкәт.

3. Муниципаль районның милек объектлары муниципаль район муниципаль мөлкәт реестрында исәпкә алына.

4. Муниципаль район җирле үзидарә органнары, гамәлдәге законнар нигезендә, муниципаль мөлкәткә мөстәкыйль ия булалар, алардан файдаланалар һәм эш итәләр.

5. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яисә даими файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә аерып алырга, башка килешүләр төзергә, шартнамәләрдә һәм килешүләрдә тапшырыла торган мөлкәттән файдалану шартларын билгеләргә хокуклы.

6. Муниципаль районның муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе муниципаль район Советы карары белән билгеләнә.

7. Муниципаль мөлкәт белән идарә итүне әлеге Устав һәм муниципаль район Советының норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 81 статья. Районның муниципаль мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм эш итү

1. Районның җирле үзидарә органнары, әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләр бүлешүне исәпкә алып, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм район җирле үзидарә органнарының алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль мөлкәткә мөстәкыйль ия булалар, файдаланалар һәм алар белән эш итәләр.

2. Районның җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яисә даими файдалануга тапшырырга, аерып алырга, федераль законнар нигезендә башка килешүләр кылырга хокуклы.

3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль законнар нигезендә җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнә. Муниципаль мөлкәтне файдаланудан керемнәр җирле бюджетларга керә.

**82 статья. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык оешмалары**

1. Район әлеге Устав билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне төзергә, үзгәртеп корырга һәм бетерергә, хуҗалык җәмгыятьләре төзүдә, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле муниципальара оешмалар төзүдә катнашырга хокуклы. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең максатларын, шартларын һәм эшчәнлек тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, әлеге предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләрен вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфасыннан азат итә, аларның эшчәнлеге турында әлеге Уставта каралган тәртиптә хисапларны тыңлый.

3. Җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидиар җавап бирәләр һәм аларны федераль законда билгеләнгән тәртиптә үтәүне тәэмин итәләр.

**83 статья. Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре**

Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар белән, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре законнарда башкасы билгеләнмәсә, шартнамә нигезендә төзелә.

## XIV бүлек. РАЙОННЫҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

**84 статья. Район Бюджеты**

1. Районның үз бюджеты бар.

2. Район бюджеты өч елга (чираттагы финанс елы һәм план чоры) төзелә һәм раслана.

3. Район бюджеты проектын төзү һәм карау, район бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, район бюджеты үтәлеше турында хисап төзү, Россия Федерациясе Бюджет кодексында, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләрне үтәп, муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла.

4. Район бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә район башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда, аның район Советы карары белән расланган бюджет корылышы һәм районның бюджет процессы турындагы Нигезләмәсе таләпләрен үтәп төзелә.

5. Район бюджеты проектын карау, район бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, район бюджеты үтәлеше турында хисап төзү тәртибе район Советы карары белән расланган бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.

Район бюджеты турындагы карар Россия Федерациясе Бюджет кодексының 5 статьясында каралган тәртиптә үз көченә керә.

6. Район бюджетының үтәлешен районның Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Район бюджеты үтәлешен контрольдә тотуны район Советы гамәлгә ашыра.

**85 статья. Районда бюджет процессы**

1. Район бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешенә контроль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла. Район бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

2. Җирле бюджет проекты, җирле бюджетны раслау турындагы карар, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, җирле бюджетны үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны турында квартал саен белешмәләр, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны күрсәтеп, рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Район бюджеты проектын төзү районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар, алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Район бюджеты проекты район Советының муниципаль хокукый акты нигезендә өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

5. Район бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә районның Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда, аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә төзелә.

6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын төзү

түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, Биектау муниципаль районының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсешкә фараз;

озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы үзгәрешләре проекты);

муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программалар проектлары).

7. Бюджет турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (профициты) керә торган бюджетның төп характеристикалары, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Россия Федерациясе субъектлары законнарында, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының муниципаль хокукый актларында (бюджет турындагы законнардан (карарлардан) тыш) билгеләнгән башка күрсәткечләр булырга тиеш.

Район бюджеты турында район Советы карарында шәһәр, авыл җирлекләре (шәһәр эчендәге районнар) бюджетлары арасында алар Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнмәгән очракта керемнәрне бүлү нормативлары булырга тиеш.

8. Район бюджеты турындагы карар белән составлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары, район Советының муниципаль хокукый актлары нигезендә кабул ителгән күрсәткечләр раслана.

9. Район бюджеты турындагы карар белән түбәндәгеләр билгеләнә:

Район бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

бюджет ассигнованиеләрен чыгым төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) яки чыгым төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, чыгымнар төрләренең һәм (яисә) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләренең максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук әлеге Кодекста, Татарстан Республикасы законында, район Советы хокукый актында билгеләнгән очракларда бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү;

чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

гавами норматив йөкләмәләрне башкаруга җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

бюджетара трансфертларның башка бюджетлардан алына торган һәм (яки) чираттагы финанс елында һәм план чорында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган күләме;

план чорының беренче елына район бюджеты чыгымнарының шартлы расланучы (расланган) чыгымнарының гомуми күләме район бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнешкә ия Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджет чыгымнарын исәпләмичә), план чорының икенче елына Район бюджеты чыгымнарының кимендә 5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнешкә ия Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган бюджет чыгымнарын исәпләмичә);

чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары;

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексының (алга таба - РФ Бюджет кодексы) 184.1 статьясындагы 3 пунктының унынчы абзацы нигезендә чираттагы финанс елыннан соң һәм план чорының һәр елыннан соң килүче 1 гыйнварына торышы буенча муниципаль эчке бурычның югары чиге һәм (яисә) дәүләт муниципаль тышкы бурычының югары чиге, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге күрсәтелеп;

район бюджетының Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, район Советының муниципаль хокукый актларына туры китереп билгеләнгән башка күрсәткечләре.

10. Район бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта район Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә документлар һәм материаллар тапшырыла.

11. Район бюджеты турындагы карар проектын карау һәм аны район Советының муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән раслау тәртибе бюджет турындагы карарның чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан үз көченә керүен, шулай ук күрсәтелгән карар белән күрсәткечләрне һәм характеристикаларны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясы нигезендә раслауны күздә тотарга тиеш.

12. Район бюджеты турындагы карар 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында яисә район бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса.

Район бюджеты турындагы карар билгеләнгән тәртиптә имзаланганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

13. Районның җирле үзидарә органнары район бюджетының баланслылыгын, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, дефицит күләме, муниципаль бурыч күләме һәм структурасы, районның бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы законнарының һәм федераль

законнарның үтәлешен тәэмин итә.

14. Район бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә төзелә.

15. Район бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган формаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга район бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру рөхсәт ителми, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш.

16. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

**86 статья. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**87 статья. Район гражданнарының үзара салым акчалары**

1. Муниципаль районның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрен хәл итү өчен гражданнарның бер тапкыр түләүләре - гражданнарның үзара салым акчалары җәлеп ителергә мөмкин. Мондый түләүләрнең күләме муниципаль район халкы өчен абсолют бертигез күләмдә билгеләнә, моңа муниципаль район (муниципаль район чикләрендәге авылара территориядә урнашкан торак пункт) халкының гомуми санынннан 30 %тан арта алмаган һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган аерым категория гражданнар керми.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер мәртәбә түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

**88 статья. Районның муниципаль бурыч алуы (муниципаль бурычы)**

1. Муниципаль бурыч алу дигәндә, муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру юлы белән һәм заемчы буларак гавами-хокукый оешманың бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар рәвешендә гавами-хокукый оешма бюджетына заем акчаларын гавами-хокукый оешма исеменнән җәлеп итү күздә тотыла.

Районның Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясеннән читтә бурыч алуы рөхсәт ителми.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә муниципаль

берәмлек исеменнән муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашыру хокукына район Башкарма комитеты ия.

**89 статья. Районның җирле бюджеты үтәлеше**

1. Районның җирле бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Район бюджеты кассаларның бердәмлегенә һәм чыгымнарның ведомствога буйсынуына нигезләнеп үтәлә.
3. Район бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, район бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
4. Район бюджетының үтәлеше районның җыелма бюджет язмасы һәм районның касса планы нигезендә оештырыла.

**90 статья. Бюджет хисабы. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап**

1. Районның бюджет хисабы еллык.
2. Районның бюджет хисаплылыгы районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә төзелә һәм район Башкарма комитетына тапшырыла.
3. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап Район Советы карары белән расланырга тиеш.
4. Районның Финанс-бюджет палатасы муниципаль районның берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында Россия Федерациясе субъектының финанс органына бюджет хисабы тапшыра.
5. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап, аны район Советына тапшырганчы, тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең) бюджет хисабын тышкы тикшерүне һәм район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап буенча бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

Район бюджетының үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, әлеге Устав һәм муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Район составына керүче җирлекнең вәкиллекле органы мөрәҗәгате буенча җирлек бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Районның Башкарма комитеты агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча район бюджетының үтәлеше турында хисап тапшыра. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап буенча бәяләмә әзерләү бюджет акчалары баш бүлүчеләрнең еллык бюджет хисабының еллык бюджет тикшерүе күрсәткечләре нигезендә 1 айдан артмаган срокта уздырыла.

6. Ел саен, агымдагы финанс елының 1 маеннан да соңга калмыйча, районның Башкарма комитеты хисап финанс елына район бюджеты үтәлеше турында еллык хисабын район Советына, район бюджетының үтәлеше турында район Советының

карар проектын, район бюджетының үтәлеше турында башка бюджет хисабын, районның берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында бюджет хисабы һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган башка документларны теркәп тапшыра.

7. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча район Советы район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

8. Район Советы район бюджетының үтәлеше турында еллык отчет кире кагылу очрагында, ул күрсәткечләрне дөрес чагылдырмау яисә тулысынча чагылдырмау фактларын бетерү һәм бер айдан да артмаган срокта кабат тапшыру өчен кире кайта.

9. Район бюджетының үтәлеше турындагы карар белән, район бюджетының керемнәренең, чыгымнарының һәм дефицитының (профицитының) гомуми күләмен күрсәтеп, хисап финанс елы өчен район бюджетының үтәлеше турында хисап раслана. Хисап финанс елында район бюджетының үтәлеше турында район Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәгеләрнең күрсәткечләре раслана:

бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары буенча район бюджеты керемнәренең;

район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча район бюджеты чыгымнарының;

бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча район бюджеты чыгымнарының;

бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча бюджетлар кытлыгын финанслау чыганакларының.

Район бюджетын үтәү турындагы карар белән шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законында, район Советының муниципаль хокукый актында район бюджетын үтәү турындагы карар өчен билгеләнгән башка күрсәткечләр раслана.

**91 статья. Муниципаль финанс контроле**

1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм башка норматив хокукый актларны үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, башлангыч һәм аннан соңгы финанс контроленә бүленә.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле район Башкарма комитеты органнары (вазыйфаи затлары) булган муниципаль финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.

4. Якынча контроль җирле бюджетны үтәү барышында бюджет хокук бозуларын кисәтү һәм булдырмау максатларында гамәлгә ашырыла.

5. Алдагы контроль аларны үтәүнең законлы булуын, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатларында район бюджетын үтәү

нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## XV бүлек. РАЙОН УСТАВЫН КАБУЛ ИТҮ. ӘЛЕГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ

### 92 статья. Район уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе

1. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проекты район Башлыгы, район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты Җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан район Советына кертелә ала.

2. Район уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен район Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга мөмкин.

3. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проекты, аларны караган көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, район Советы тарафыннан күрсәтелгән Устав проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, район Советының күрсәтелгән карары проекты буенча бер үк вакытта бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, шулай ук гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибе рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устав) һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында, район Уставы нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның әлеге фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

4. Район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул түбәндәгечә рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) район Советының (гражданнар җыены) аның рәисе һәм район башлыгы имзалаган, яки район Советы рәисе вәкаләтләрен (гражданнар җыенын) берүзе башкаручы район башлыгы тарафыннан имзаланган карары;

2) район Советы (гражданнар җыены) кабул иткән һәм район Башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актта аны кабул итү турындагы район Советы (гражданнар җыены) карарының реквизитлары күрсәтелә. Мондый карарга район Советының күчмә нигезләмәләрен һәм (яисә) район уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турындагы нормаларын кертү рөхсәт ителми.

5. Район уставын яңа редакциядә бәян итү район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән кую рөхсәт ителми. Бу очракта районның яңа уставы кабул ителә, ә районның элек гамәлдә булган уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар районның яңа уставы үз көченә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.

6. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары нигезендә, аларны район Советы сессиясендә карау алдыннан гавами тыңлаулар уздырыла, Уставка үзгәрешләр бары тик җирле әһәмияттәге мәсьәләләр Уставында беркетелә торган мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү буенча вәкаләтләрне Россия Федерациясе Конституциясенә һәм федераль законнарга туры китерү максатларында кертелә торган очраклардан тыш.

**93 статья. Район Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Район уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын карау район Советы тарафыннан район Советы регламенты нигезендә кимендә ике укылышта гамәлгә ашырыла.

2. Район уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң, күрсәтелгән проект төзәтмәләр кертү өчен район Башлыгы тарафыннан хокук чыгару инициативасы хокукы субъектларына җибәрелә.

3. Район Уставы, Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан өчтән ике өлештә күпчелек тарафыннан кабул ителә.

**94 статья. Район Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар**

1. Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары кабул ителгәннән соң район Башлыгы тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен юллана.

2. Район Уставы, район Советының әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карары дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чykканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә. Район башлыгы теркәлгән район Уставын, район Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый актны, муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән алып, җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.

Район уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары аларны дәүләт теркәвеннән соң районның торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т/юл станциясе бис., Кооперативная ур., 5 й., һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru / веб - адресы, шулай ук Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» порталында (http://pravo-minjust.ru, http://право-

минюст.рф, челтәр басмасы сыйфатында теркәү: Эл № ФС77-72471 05.03.2018) рәсми бастырылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көчләренә керәләр.

3. Уставка кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (Уставны федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук район Башлыгын һәм башка җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары вәкаләтләре үзгәрү, вәкаләтләре сроклары, сайлау тәртибе үзгәрүдән тыш), Уставка күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән район Советы вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

4. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул түбәндәгечә рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) район Башлыгы кул куйган район Советы карары;

2) район Советы кабул иткән һәм район Башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актта аны кабул итү турындагы район Советы карарының реквизитлары күрсәтелә. Уставка кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында район Советының күчеш нигезләмәләрен һәм (яисә) нормаларын кертү рөхсәт ителми.

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт итеп Уставны яңа редакциядә бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта яңа Устав кабул ителә, ә моңа кадәр гамәлдә булган Устав һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар яңа Устав үз көченә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип таныла.

Моннан тыш, 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» Федераль законның 3 статьясының 3 өлеше нигезендә муниципаль берәмлек уставында титул кәгазе бар, ул муниципаль берәмлек уставы реквизитларын үз эченә ала һәм аның битләре белән бергә тегеп куела.